Россия Федерациясенең мәгариф һәм фән министрлыгы
«Казан (Идел буе) федераль университеты» югары профессиональ белем бирү федераль дәүләт автономияле мәгариф учреждениесе

Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

В.З.ГАРИФУЛЛИН

Лекцияләр конспекты

Казан 2014

Гарифуллин В.З.

Информационная журналистика: Курс лекций (на татарском языке) / Гарифуллин В.З.; Казанский (Приволжский) федеральный университет. – Казань, 2014. – 65 с.

Предлагаемые лекции посвящены изучению функционирования информационных жанров в современной журналистике. Основное внимание в курсе уделяется изучению теории жанров в журналистике. Рассматриваются жанровые разновидности журналистских произведений и особенности работы над материалами разных жанров. Предусматривается изучение особенностей новостного формата в современной татарской журналистике, технологии работы над текстами информационного характера

Электронная версия курса: http://zilant.kpfu.ru/course/view.php?id=17360

Утвержден на заседании кафедры татарской журналистики
Протокол №6 от 12.12.2013

© **Казанский федеральный университет**

© **Гарифуллин В.З.**

Направление подготовки: 031300.62 – Журналистика, профиль: Средства массовой информации (национальная журналистика) (бакалавриат, 2 курс, очное обучение)

Дисциплина: «Основы журналистской деятельности», **модуль:** "Информационная журналистика"

Количество часов: 36 ч. (в том числе: лекции – 18, практические занятия – 18), форма контроля: зачет.

Темы: 1. Журналистика жанрлары. 2.Журналистикада жанр төркемнәре.
Хәбәри жанрлар. 3. Хәбәр. 4. Хәбәрдә журналист бәясе. 5. Хисап жанры. 6. Репортаж жанры. 7. Репортаж жанрында эшләүнең технологиясе. 8. Интервью. 9. Интервьюның үсеш юллары.
1. Жанры журналистики. 2. Группы жанров в журналистике. Информационные жанры. 3. Заметка. 4. Журналистская оценка в заметке. 5. Отчет. 6. Жанр «репортаж». 7. Технология работы в жанре репортажа. 8. Интервью. 9. Перспективы развития интервью.
Ключевые слова: журналистика жанры, мәгълүмат, хәбәр, хисап, интервью, репортаж
жанр журналистики, информация, заметка, отчет, интервью, репортаж

Дата начала эксплуатации: 1 сентября 2014 года

Автор-составитель: Гарифуллин Васил Загитович, профессор кафедры татарской журналистики Института массовых коммуникаций и социальных наук, доктор филологических наук

ЭЧТӘЛЕК

1. Журналистика жанрлары. 4

2.Журналистикада жанр төркемнәре.

Хәбәри жанрлар 7

3. Хәбәр 9

4. Хәбәрдә журналист бәясе. 18

5. Хисап жанры 23

6. Репортаж жанры. 28

7. Репортаж жанрында эшләүнең технологиясе...................................... 34

8. Интервью 42

9. Интервьюның үсеш юллары 54

Әдәбият исемлеге 62

Өстәмә әдәбият исемлеге 63

Журналистика жанрлары

Жанрларны өйрәнү – бүгенге журналистика теориясенең үзәк мәсьәләләреннән берсе. Газета-журналларда басылган, радио һәм телевидение аша яңгыраган һәрбер әсәр билгеле бер жанр кысаларында иҗат ителә. Аның эчтәлеге дә, формасы да шушы жанр таләпләре нигезендә оеша.

Бу фикер белән килешмәүчеләр дә бар: янәсе, журналист үзенең әсәрен иҗат иткәндә нинди жанрда эшләве турында баш ватып тормый. Чынлап та, иҗат процессында газета әсәре язучы аерым жанр закончалыклары, жанрның чикләре турында уйламаска да мөмкин. Ләкин ул ирексездән, интуитив рәвештә булса да, үзенең элгәрләре тулпаган тәҗрибәгә таянырга мәҗбүр. Ә бу тәҗрибә, иң беренче чиратта, жанрларның закончалыкларына нигезләнә. жанр тормышның нинди дә булса өлкәсен, ягын танып-белү, аны укучыга җиткерүнең сыналган, типиклашкан алымнарын һәм формаларын берләштерә. Шуңа күрә теге яки бу жанрның теманы яктырту, проблеманы чишүдәге мөмкинлекләрен үзләштерү журналистның эшен күпкә җиңеләйтә.

Жанрларның күбесе дистәләрчә еллар аша сынау үткән, камилләшкән, йөзләрчә журналистларның иҗат табышларын үзенә туплаган. Көн сааен «табадан төшеп торучы» газета-журналлар бу тәҗрибә-табышларны типиклаштырган. Һәр жанрның үзенә генә хас тематик, композицион, стилистик алым һәм чаралары, закончалыклары барлыкка килгән. Аларны белмичә торып, вакытлы матбугатны тулы канлы язмалар белән даими тәэмин итеп тору мөмкин түгел…

Аерым фәнни хезмәтләрдә татар вакытлы матбугатының кайбер жанрлары, аларның тарихы, тел-стиль һ.б. үзенчәлекләре яктыртылса да[1],

[1] Кашшаф Г. Очерк в газете// Мастерство очеркиста. – Казань, 1970. С.3-15; Нуруллина Р.М. Татарский советский очерк 20-ых годов //Там же. С.16-29; Нуруллина Р.М. Жанры в газете «Чулпан» // Жанры журналистики. – Казань, 1972. – с.79-97; Гыймадиев Ү.И. Сатира коралы белән. – Казан, 1977. – 215 б.; Низамов И.М. Матбугатның тәэсирле сүзе. – Казан, 1981. – 144 б.; Әгъзамов Ф.И. Үзәктә – кеше. – Казан, 1981. – 144 б.; Әгъзамов Ф.И. Тукай – журналист.

турыдан-туры жанрлар теориясен өйрәнүгә багышланган махсус тикшеренүләр юк. Тәкъдим ителә торган уку ярдәмлеге – шушы юнәлештә ясалган бер адым.

Әдәбият-сәнгатьнең төрле тармакларында (музыкада, әдәбиятта, сынлы сәнгатьтә һ.б.) «жанр» термины төрле мәгънәгә ия. Әдәбият теориясендә жанрга менә мондый билгеләмә бирелә: «Жанр (французча «төркем» мәгънәсендә) – әдәбият белемендә әдәби әсәрләрнең тарихи рәвештә барлыкка килгән тибын белдерә. Жанр төшенчәсендә кайсы да булса дәвердә, милләттә яки бөтендөнья әдәбиятындагы зур төркем әсәрләргә хас сыйфатлар гомумиләштерелә. Әдәбият белемендә жанр өч яктан билгеләнә: 1) уртак эстетик сыйфатлары нигезендә нинди дә булса әдәби төргә керүе белән (сатирик, патетик, трагик төрләр); 2) әсәрнең күләменә карап; 3) образлар төзү ысулларына карап (символик, аллегорик, документаль жанрлар)».[2]

Вакытлы матбугатта жанр журналистика әсәренең шулай ук тарихи рәвештә барлыкка килгән һәм ныклы сыйфатларга ия булган тибын белдерә. Тик биредә жанрлар бер-берсеннән башка төрлерәк критерийлар нигезендә аерыла. М.С.Черепахов фикеренчә, бу критерийлар түбәндәгеләр: 1) танып-белү предметының, яктыртыла торган объектның характеры; 2) әсәрнең функцияләре; 3) чынбарлыкны яктыртуның киңлеге һәм нәтиҗә-йомгакларның масштабы; 4) стилистик чаралар төрлелеге.[3] Кайбер теоретиклар әсәрнең күләменә дә игътибар итү кирәклеген искәртәләр.

Вакытлы матбугаттагы теге яки бу жанрның үзенчәлекләрен өйрәнгәндә, иң беренче чиратта, югарыда санап үтелгән сыйфатлардан чыгып эш итәргә кирәк. Игътибар итсәгез, алар арасында әсәрнең эчтәлегенә дә, формасына да бәйле булганнары бар. Димәк, жанр эчтәлек һәм форманың аерылгысыз бердәмлеген чагылдыра.

Билгеләмәбездән күренгәнчә, жанр - тарихи төшенчә. Жанрлар вакытлы матбугат үсешенең төрле этапларында барлыкка килгән һәм камилләшкән.

– Казан, 1986. – 271 б.; Хәбәрче буласың килсә… /Төз.И.К.Сәмигуллина. – Казан, 1984. – 96 б. һ.б.

[2] Әдәбият белеме сүзлеге /Төз.ред.А.Г.Әхмәдуллин. – Казан, 1990, - 52 б.

[3] Черепахов М.С. Проблемы теории публицистики. – М., 1973. – С.14.

Тарихның бер чорында өстенлек иткән жанрларның урынын икенче чорда башка төрле жанрлар ала. Башлангыч этаплар өчен хәбәри жанрлар гына хас булса, соңрак аналитик һәм әдәби-публицистик характердагы яңа жанрлар барлыкка килгән. Татар матбугатының туган чоры, шул исәптән газета-журналлардагы төп жанрларның формалашкан вакыты булып XX йөз башы, беренче рус революциясе еллары исәпләнә. Бу елларда хисап, мәкалә, рецензия, күзәтү кебек жанрлар киң кулланыла, сатирик жанрлар аеруча көчле үсеш ала. Вакытлы матбугатыбыздагы күпчелек жанрларны үстерүгә К.Насыйри, И.Гаспралы, Г.Исхакый, Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г. Коләхмәтов, Г.Ибраһимов, Ф.Бурнаш, В.Шәфигуллин, Г.Килдебәков, Ш.Әхмәдиев, Ф. Сәйфи-Казанлы һ.б. язучы һәм журналистлар зур өлеш керткән. Аңлашыла ки, журналистика жанрларының шактые (очерк, тасвирнамә, памфлет) матур әдәбият тәэсире белән барлыкка килган һәм камилләшкән.

Вакытлы матбугат жанрлары һаман үсештә, үзгәрештә. Иҗтимагый тормыштагы үзгәрешләр, массакүләм информация чараларындагы яңа тенденцияләр жанрлар системасында да чагылыш тапмый калмады. Әйтик, элеккеге елларда газетада иң мөһим жанрлардан исәпләнгән баш мәкалә жанры хәзер бөтенләй кулланылмый диярлек. Аның функцияләре мәкаләнең икенче төрләренә яки бөтенләй башка жанрларга күчте. Хисап жанрының "парламент хәбәре" дип аталучы үзенчәлекле формасы туды. Интервьюның яңадан-яңа төрләре, шул исәптән заманча технологияләр белән бәйлеләре, барлыкка килеп тора Башка жанрларда да шактый үзгәрешләр күзгә ташлана.

Жанр үзгәрешләре - теге яисә бу жанрда эшләүгә иҗади якын килү, эзләнү нәтиҗәсе. Жанр никадәр генә ныклы сыйфатларга ия булмасын, әгәр журналист бу жанрның үзенчәлекләрен һәм закончалыкларын иҗади үзләштермәсә, әсәрендә үзенең шәхси йөзен чагылдырмаса, ул укучыны кызыксындыра алмаячак. Шуңа күрә искәртү урынлы булыр: жанрлар теориясен өйрәнү - журналист осталыгын билгеләүче куп санлы шартларның бары тик берсе.

Журналистикада жанр төркемнәре.
Хәбәри жанрлар

Журналистика алдына куела торган бурычлар бер генә төрле түгел. Бер очракта нинди дә булса вакыйга-факт турында хәбәр генә итәргә, икенче очракта аның әһәмиятен аңлатырга, бәя бирергә кирәк, ә өченче очракта берәр төрле күренеш яисә аңа мөнәсәбәте булган кеше турында җанлы-тәэсирле формада сөйләп бирү мөһим. Бурыч һәм функцияләреннән чыгып, вакытлы матбугат жанрларын өч зур төркемгә тупларга мөмкин: 1) хәбәри жанрлар, 2) аналитик жанрлар, 3) әдәби-публицистик жанрлар.

Хәбәри (информацион) төркемгә керүче хәбәр, хисап, репортаж һәм интервью жанрларының төп функциясе – иҗтимагый әһәмияткә ия булган яңалыкны укучыга оператив хәбәр итә. Аналитик жанрларның (бу төркемгә мөхбирнамә, мәкалә, хат, рецензия, күзәтү керә) төп максаты исә нинди дә булса проблеманы чишү юлларын эзләү, вакыйгаларга, күренешләргә анализ бирү. Әдәби-публицистик жанрлар (тасвирнамә, очерк, парча, фельетон, памфлет) зур гомумиләштерү көченә ия һәм алар тормышыбыздагы аерым күренешләр турында эмоциональ фикер йөртү, кешенең характерын ачып бирү, кимчелекләрдән ачы көлү максатында эшкә жигелә.

Билгеле, жанрларның әлеге төркемнәре шартлы рәвештә генә аерып чыгарыла. Теоретик әдәбиятта башка төрле бүленешләрне дә очратырга мөмкин. Мәсәлән, И.М.Низамов жанрларны бары ике төркемгә: хәбәри һәм тасвирый характердагы жанрларга бүлә[4]. Рус галимнәренең хезмәтләрендә дә бүленешләр төрле[5]. Бу факт үзе үк жанр төркемнәре арасында ныклы чикләр булмавын дәлилли. Хәбәри жанрларда анализ элементлары булган кебек, аналитик жанрда иҗат ителгән язмалар да укучы өчен яңа мәгълүмат бирә ала. Шул ук вакытта һәм хәбәри, һәм аналитик жанрларда әдәби-публицистик әсәрләр өчен хас булган хиссилек һәм образлылык урын алырга мөмкин.

---

[4] Низамов И.М. Күрсәтелгән хезмәт. – 121 б.

[5] Кара: Пельт В.Д. Дифференциация жанров газетной публицистики. – М., 1984. – С.19-20.

Хәзер югарыда санап үтелгән төркемнәрнең берсенә – хәбәри жанрларга, аларның төп сыйфатлары, үзенчәлекләре һәм закончалыкларына тукталабыз.

Аралашу, информация алмашу - кешелек яшәешенең мөһим алшартларыннан берсе. Дөньяда, илебездә, республикабызда, авылда һәм шәһәрдә, сәясәттә һәм икътисадта, рухи һәм көндәлек тормышта көн саен яңадан-яңа вакыйгалар булып тора. Яңалыкларны халыкка җиткерүнең иң нәтиҗәле каналы - массакүләм мәгълүмат чаралары. Вакыйга/факт турындагы хәбәрне оператив рәвештә укучыга ирештерү функциясен башкаручы хәбәри жанрлар вакытлы матбугатта киң кулланыла торган иң әһәмиятле жанрлардан исәпләнә. Теләсә кайсы газетаның бер генә саны да алардан башка чыкмый. Нинди генә матбугат органында эшләмәсен, нинди генә темага язмасын – хәбәри жанрга һәр журналист мөрәҗәгать итә. Шуңа күрә дә әлеге төркемгә керүче жанрларның закончалыкларын, уртак һәм аермалы сыйфатларын үзләштерү журналист булырга әзерләнүче студент өчен аеруча зарури.

Югарыда искә алынган төп функция - оператив хәбәр итү функциясе – хәбәри жанрларны бер төркемгә туплап өйрәнергә мөмкинлек бирә, аларга хас уртак билгеләрнең сәбәпчесе булып тора.

Бу уртак билгеләрнең иң беренче күзгә ташлана торганы - информативлык, ягъни, язманың укучы өчен кирәкле, кызыклы яналыкка ия булуы. Журналистика теориясендә информация билгеле бер максатлардан чыгып сайлап алынган, социаль әһәмияткә ия булган факт яки фактлар җыелмасы дип анлатыла[6]. Димәк, хәбәри жанрлар, кагыйдә буларак, социаль әһәмияткә ия булган яңалыкны хәбәр итә.

Икенче мөһим билге – оперативлык. Вакыйга яки факт турындагы язма газета битендә тиз арада дөнья күрмәсә, үзенең актуальлеген югалта. Оперативлык - информатив язмаларның һәм, гомумән, матбугат органының

[6] Бу урында «информация» сүзенең еш кына конкрет жанр (гадәттә хәбәр жанры) мәгънәсендә файдаланылуын әйтеп үтәргә кирәк. Ләкин фәнни әдәбиятта аны жанр атамасы буларак куллану урынсыз. Фәнни термин буларак, ул бер генә мәгънәгә, югарыда күрсәтелгән мәгънәгә ия.

кыйммәтен билгеләүче иң мөһим факторлардан санала. Ул үз чиратында хәбәри жанрлар өчен характерлы булган тагын бер уртак сыйфатны билгели: материалларның күләме җыйнак. Чөнки журналистның максаты тәфсилләү түгел, ә мәгълүматны тиз арада укучыга җиткерү, хәбәр итү генә.

Документальлек һәм төгәллек – хәбәри жанрларның аерылгысыз билгесе. Аларда сүз конкрет урын һәм вакыт, конкрет вакыйгалар турында бара. Шуңа күрә бу жанрларда и?ат итүче аеруча төгәл һәм объектив булырга тиеш.

Уртак яклары белән беррәттән жанрларның һәрберсен аерып торучы үзенчәлекле билге һәм сыйфатлар да шактый.

Контроль сораулар:

1. Журналистикада "жанр" төшенчәсе нәрсәне аңлата?
2. Сез нинди жанр төркемнәрен беләсез?
3. Хәбәри төркемгә кайсы жанрлар керә?
4. Хәбәри жанрларга нинди уртак сыйфатлар хас?

Бирем:

Бер үк газетаның берничә санына анализ ясап, аның жанрлар составын ачыклагыз.

Хәбәр

Хәбәр - газетадагы иң традицион һәм иң киң таралган жанр. Вакытлы матбугат белән бер ук чорда барлыкка килсә дә, ул бүген дә үзенең әһәмиятен югалтмаган. Ул, кагыйдә буларак, мөһим бер факт/вакыйганы тиз генә укучыга хәбәр итү максатында кулланыла һәм гадәттә "нәрсә?", "кайда?", "кайчан?" дигән сорауларга җавап бирә. Жанрның күләм ягы чикле: язмалар күп очракта бер яки берничә абзацтан артмый.

Хәбәрнең төрләре берничә: хроника-хәбәр, аңлатмалы-хәбәр, тойгылы хәбәр. Бу жанр кысаларына хат-хәбәрне дә кертергә була.

Хроника хәбәр – күләме ягыннан иң кечкенә хәбәр төре. Анда хәбәр ителергә тиешле факттан тыш берни да әйтелми. Хроника-хәбәрнең бер генә җөмләдән торганнары да очрый:

Татарстан Республикасы дәүләт киносында “Таң батыр” дигән татар халык әкияте мотивларына нигезләнгән беренче милли мультфильмны монтажлау эшләре төгәлләнде (Мәдәни җомга, алга таба - М.?.).

Хроника-хәбәрдә вакыт мөнәсәбәтләре гадилеге белән аерылып тора. Текст эчендә гадәттә бер генә вакыт планы була. Текстның оперативлыгы, аны төгәл һәм икеләнүләрсез аңлау кирәклеге вакыт белдерү формаларын гади, аңлаешлы һәм конкрет куллануны таләп итә. Күпчелек очракта вакыйганың датасын төгәл күрсәтү сорала. Аеруча мөһим вакыйгалар турында хәбәр ителгәндә, эш-хәрәкәтнең сәгате, минуты да күрсәтелергә мөмкин.

Вакыт белдерүче тел чарасының аеруча әһәмиятен истә тотып, аны текстның башлам өлешенә үк чыгару очраклары еш күзәтелә:

12,13,14 октябрь. Казан сәнгать училищесы үзенең 100 еллык юбилеен билгеләп үтә (М.?.).

Нәкъ шул рәвешчә текстның башламына вакыйганың башка кайбер параметрлары чыгарыла. Мондый параметрларга түбәндәгеләр керә:

а) вакыйганың урыны:

Мари Эл. Бәрәңге районында Республика татар мәдәният үзәге ачылды (Ватаным Татарстан – алга таба В.Т.).

б) мәгълүмат чыганагы:

Татар-информ. Мәскәүдән сөенечле хәбәр килде: каланың төньяк өлешендә, Отрадноеда, яңа мәчетнең нигез ташын салу тантанасы булды (В.Т.).

в) мәгълүмат алу ысулы:

Лениногорск (<u>телефон буенча</u>). 12 май. Үткән төндә бөтен төбәкне иңләпе җҗылы яңгыр яуды (В.Т.).

г) төп тема:

<u>Армспорт</u>. Чиләбе шәһәрендә үткән Русия чемпионатында Татарстан спортчылары 10 алтын, 5 көмеш, 9 бронза медаль яуладылар. (Татарстан яшьләре, алга таба - Т.я.).

Кайвакыт башламда мондый элементларның берничәсе дә була ала. Әйтик, заманында газеталарыбыз совет космонавтларының галәмдә очышына көндәлек күзәтү ясап барган вакытта менә мондый калып кулланалар иде:

<u>Очышны идарә итү үзәге</u>. <u>12 февраль</u>. <u>ТАСС</u>. Владимир Титов һәм Муса Манаровның "Мир" орбиталь комплексы бортындагы чираттагы эш атналары төгәлләнде... (В.Т.)

Бу урында шуны да әйтеп узарга кирәк, текстны югарыда искә алынган алым нигезендә оештыру — яңалык түгел. Ул төрле чорда чыккан газеталар өчен, әйтик, гасыр башы матбугаты өчен дә характерлы:

<u>Вятка</u>. Алабуга өязендәге мәктәп шәкертләре арасында ачлык бик куәтле булып, һәр мәктәптә йөзләп һәм икешәр йөзләп бала ярдәмгә мохта. Ләкин боларга ярдәм юк дәрәҗәсендә аз. Фәкать мәктәп башына 8 сум яки 10 сум гына чыгадыр. (Бәянелхак, 1912, 13 гыйнв.).

Хроника-хәбәрнең мәгълүмати тыгызлыкка омтылышы нәтиҗәсесендә аның "кодлаштырылган хәбәр" дигән төре дә формалашкан. Менә шундый текстларның берсе:

Хоккей. РХЛ беренчелеге. 12 ноябрь. "Ак барс" - "Торпедо" (Ярославль) - 2:0 (0:0; 1:0; 1:0) (Т.я.).

Әлеге язма, кыска гына булса да, спорт сөюче өчен зур кыйммәткә ия. Беренчедән, ул гаять оператив. Икенчедән, шактый бай мәгълүмат бирә: мондый төр язмаларга күнеккән газета укучы хоккей матчында кайсы шәһәр командасының нинди исәп белән җиңүен генә белән калмыйча, аерым периодларда исәпнең ничек үзгәрүе хакында да хәбәрдар була.

Татар газеталарындагы хроника-хәбәрләр турыдан-туры мәгълүмат җиткерүдән тыш өстәмә рәвештә түбәндәге функцияләрне дә башкара: конкретлаштыру, аңлату, аныклау, сыйфатлау, капма-каршы кую, сәбәп, нәтиҗә һ.б. Мәсәлән:

"КамАЗ"дагы янгын предприятиегә шактый зыян китерде. Шуңа күрә Казанның яшь тамашачылар театры артистлары "Гамлет" музыкаль драмасының премьерасыннан килгән керемнәрне Чаллыга җибәрергә булдылар (Шәһри Казан, алга таба – Ш.К.).

Биредәге җөмләләр арасында сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәте урнашкан: беренче җөмлә икенче җөмләдә хәбәр ителә торган фактның сәбәбен ачыклап бирә. Хроника-хәбәрнең менә шул төр фикерләүгә корылганнары да, киресенчә ысул белән төзелгәннәре дә шактый еш очрый:

БТИҮдәге сәяси киеренкелек кимергә уйламый да. Чөнки һәр ике як үзенә күрә бер принципны саклап эш итә... (Мәгърифәт, алга таба - М.)

Бу мисалда инде икенче җөмлә беренчесендә хәбәр ителгән фактның сәбәбен ачыклый.

Хроника-хәбәрнең тел үзенчәлекләренә игътибар итсәк, аның нигездә номинатив берәмлекләрдән, терминнардан һәм газетизмнардан торуын күрербез[7]. Анда экспрессиягә, ягъни хис-кичерешләр белдерү сәләтенә ия булган лексика, эмоциональ тәгъбир һәм әйләнмәләр, тел сурәтләү чаралары очрамый диярлек. Чөнки жанрның бу төрендә автор бәясе дә, аның уй-хисләре, фикерләре дә бик аз чагыла. Хроника-хәбәрнең оперативлык һәм кыскалык кебек асыл сыйфатлары да аның теленә йогынты ясамый калмый.

Автор позициясе икенче планга кучкәнгә күрә, хәбәрнең хроникаль төрендә журналистның исем-фамилиясе бөтенләй күрсәтелмәскә мөмкин.

Хроника-хәбәрнең еш кына баш-исеме дә булмый. Бу очракта "Кичә, бүген, иртәгә", "Көн сулышы", "Соңгы сәгатьтә", "Спорт", "Яңалыклар", "Бер

[7] Низамов И.М. Күрсәтелгән хезмәт. – 122 б.

генә җөмлә белән" һ.б.ш. рубрикалар астында берничә кыска хәбәрне берләштереп бирәләр.

Хәбәр жанрының тагын бер мөһим төре булган аңлатмалы хәбәрнең дә үзәгендә бер генә вакыйга яки факт ята. Тик жанрның бу төрендә, исеменнән ук күренгәнчә, яңалык хәбәр ителү белән бергә аңа аңлатма да бирелә. Газета укучы вакыйга/фактны дөрес аңласын, аңа тиешле бәя бирә алсын өчен журналистка еш кына аның сәбәпләрен ачып бирергә, аның әһәмиятен раслаучы өстәмә дәлилләр китерергә, хәбәр ителә торган вакыйга яки фактның аерым детальләренә киңрәк тукталырга туры килә. Шунысы мөһим, өстәмә мәгълүматлар һәм фактлар, авторның фикерләре һәм бәяләре төп яңалыкны күмеп китмәсен, аны тулырак һәм кызыклырак яктыртырга ярдәм генә итсен.

Аңлатмалы хәбәрне күп кенә очракларда хроника-хәбәрнең киңәйтелгән варианты буларак карарга мөмкин. Түбәндәге текстлар жанрның шушы ике төрен чагыштырырга мөмкинлек бирә:

Гарри Каспаров белән Анатолий Карпов арасында шахмат таҗы өчен барган көреш 12:10 исәбенә җитте. Шулай итеп, Каспаров чемпион исемен саклап калды. (Т.Я.)

Шахмат таҗы – Каспаровта

Гарри Каспаров һәм Анатолий Карпов арасындагы матчның 22-нче партиясе, биш сәгатькә якын дәвам иткәннән соң, ничьяга тәмамланды. Шуның белән исәп дөнья чемпионы файдасына 12:10 булды. Гарри Каспаров шахмат таҗын үзендә саклап калды…

Гарри Каспаров шахмат таҗына беренче тапкыр 1985 елда ия булган иде. Шуннан соң 1986, 1987 һәм 1990 елларда Анатолий Карпов белән матчларда дөнья чемпионы исемен үзендә калдырды.

Илебезнең спорт журналистлары фикеренә нигезләнеп, Гарри Каспаров быел Россиянең иң яхшы спортчысы дип табылды. Дөнья чемпионы һәм кубок хуҗасы иң осталар исемлегенә кергән 10

спортчыдан шактый күп очко җыйды. /В.Т./

Бер үк яңалык ике газетада хәбәрнең ике төре аша бирелгән: хроника-хәбәр (сул багана) һәм аңлатмалы хәбәр аша. Хроника-хәбәрдә факт үзе генә хәбәр ителсә, аңлатмалысында бу фактка бәйле өстәмә мәгълүматлар да китерелә. Автор, кыскача гына булса да, төп фактны әзерләгән алшартларга һәм төп факт китергән нәтиҗәгә туктала. Шунысы игътибарга лаек, уң баганадагы текст сулдагысына караганда бер көнгә соңрак басылып чыккан. Бу аңлатмалы хәбәрдә оперативлык дәрәҗәсенең хроника-хәбәр белән чагыштырганда беркадәр түбәнрәк булуы хакында сөйли.

Әгәр башлам өлешендә төп факт/вакыйга хәбәр ителсә, аңлатмалы хәбәр тиешле нәтиҗәлелеккә ирешә, дип исәплиләр. Шул ук вакытта бу жанр төренең башкачарак үтемле композицион вариантлары да бар. Әйтик, еш кына, төп факт хәбәр ителгәнче, аңа бәйле гомуми мәгълүматлар яки аны тудырган сәбәпләр искә алына. Автор, төп факт турында сөйли башлаганчы, аның нәтиҗә-йомгакларын да хәбәр итәргә мөмкин. Укучының игътибарын җәлеп итү максатында журналистлар еш кына мавыктыргыч башлам кулланалар:

Казанда бик зур янгын чыгасы, имеш. Аны сүндерергә башка яклардан да машиналар һәм халык килергә җыена икән, дигән сүзләр йөри. Баксаң...

Алай түгел, ә пәнҗешәмбе һәм жомга көннәрендә "Тасма" берләшмәсе стадионында янгын сүндерүчеләрнең Советлар Союзы Геройлары В.Бурмистров һәм М.Фомин истәлегенә бик зур ярышлары үтәсе. Уты да, төтене дә көчле булурга мөмкин, янгын сүндерүчеләр дә аз булмаячак, Россия Федерапиясендәге дистәдән артык край, өлкә, республика вәкилләре җыела./.../ (В.Т.)

Бу язманың авторы шактый үзенчәлекле башлам уйлап тапкан: фактны иншалауга күчкәнче, ул укучыга "сенсацияле яңалык" хәбәр итә һәм шуның белән уз язмасына укучының игътибарын тарта. Бары тик шуннан соң гына, баштагы хәбәрне инкарь итеп, төп факт турында сөйли башлый. Әнә шулай,

иҗади эш итеп, аңлатмалы хәбәр жанрында кызыклы һәм оригиналь язмалар тудырырга мөмкин.

Аңлатмалы хәбәр - яңа гына узган яки булачак вакыйга яисә фактка кыскача оператив аңлатма бирүче язма. Телевидение һәм радио кебек гаять оператив информация чараларының үсүе нәтиҗәсендә газеталарда аңлатмалы хәбәрнең роле артты. Телевидение һәм радио яңалыкны халыкка оператив җиткереп торса, газетада моңа бәя, комментарий, анализ да кушыла.

Хәбәр жанрының аерым төрләре буларак, "курьер" һәм "дайджест" тибындагы хәбәрләрне дә карарга була. Аларның беренчесе урыны яки вакыты белән бергә туры килә торган вакыйгаларны туплап хәбәр итә. Мәсәлән, бер тәүлек эчендә шәһәрдә, илдә, дөньяда булган вакыйгалар, милли хәрәкәт яңалыклары, табигатьне саклау оешмаларыннан, милициядән һ.б. хәбәрдар органнардан алынган соңгы хәбәрләр. Гадәттә мондый текстта фактлар бер-берсенә бәйләп бирелми, аерым абзацлар рәвешендә, кайвакыт интерваллар аша урнаштырыла. Текстның гомуми күләме шактый зур да булырга мөмкин. Автор яңалыкларга карата үзенең мөнәсәбәтен дә белдереп бара ала.

Дайджест хәбәрләре төрле информация агентлыклары һәм массакүләм мәгълүмат чараларыннан алынган яңалыкларны берләштерә. Журналистлар андый яңалыкларның иң кызыклыларын (еш кына сенсацион булганнарын) сайлап бирергә омтылалар. Мәгълүматның чыганагын күрсәтү мәҗбүри.

Хәбәр жанрында эшләү җиңелме? Беренче карашка әллә ни авыр түгел кебек. Ләкин укучыга җиткерергә теләгән хәбәрең кызыклы да, актуаль дә, игътибарны җәлеп итәрлек тә булсын дисәң, күп йөрергә, күп эзләнергә һәм укырга, шактый иҗат михнәтләре кичерергә кирәк.

Мәгълүмат тармагында эшләүче журналист тормышның күп өлкәләре буенча белдекле булырга тиеш. Нинди да булса шәһәргә яки авылга, хезмәт коллективына барып яки телефоннан шалтыратып, "Сездә нинди яналык бар?" дигән сорауны бирү генә җитми. Башкалар өчен яналык булырлык факт журналист кызыксынган объектта инде көндәлек күренешкә әверелгән яки андагы кешеләр өчен бернинди әһәмияткә ия булмаган берәр гадәт, традиция,

эш алымы, һөнәр, яшәү рәвеше һ.б. булырга мөмкин. Яңалыкны беренче булып күреп алу өчен үзең яза торган өлкәне биш бармагың кебек белергә кирәк. Шунысы бар, хәбәрләр өчен фактлар туплаганда автор барлык объектларга да үзе барып өлгерә алмый. Бу очракта аның булышчылары - штаттан тыш хәбәрчеләр ярдәмгә килә. Алар теге яки бу урында булган вакыйганы, шунда яшәгәнгә күрә, тизрәк беләләр һәм хәбәр итә алалар. Газетаның штаттан тыш булышчылар челтәре никадәр киңрәк булса, ул кирәкле һәм кызыклы информацияне шулкадәр күбрәк һәм тизрәк урнаштыра. Хәбәр жанрында эшләүче журналист әнә шундый оператив һәм ышанычлы булышчыларга таянганда гына уңышка ирешә ала.

Тиешле мәгълүматка ия булганнан соң, аны кәгазь битенә төшерү дә журналисттан зур җаваплылык сорый. Әйткәнебезчә, хәбәр жанры автордан документальлек һәм төгәллек таләп итә. Ә бу инде фактлар, урын-вакыт атамалары, исем-фамилияләр белән эш иткәндә аеруча игътибарлы булырга кирәк дигән сүз. Шулай булмаганда, автор шактый кыен хәлдә калырга мөмкин. Бер генә мисал. Республика газеталарының берсендә менә шундый дайджест хәбәре басылып чыкгы:

"Озакламый дөньяда куркыныч яңа авыру таралачак, ул кәгазь акчаләр аша йогачак. /ТАСС/" (Т.я.)

Бу язмада факт берьяклы гына яктыртыла, дөресрәге, тулысынча яктыртылмый. Чынлыкта исә ТАСС агентлыгы югарыда китерелгән сүзләрне бер чит ил күрәзәчесенең фаразы буларак кына хәбәр иткән иде. Фактның менә шушы ягын онытып жибәрү, имеш-мимеш, фаразны абруйлы информация агентлыгы фикере дип уйларга, аңа ышанырга мәҗбүр итә, халык арасында борчу-аптыраш тудыра.

Хәбәр гади һәм аңлаешлы тел белән язылырга тиеш. Моны жанрның оперативлыгы таләп итә. Яңалыгың кызыклы һәм көн таләбенә туры килә торган булганда, укучының игътибарын җәлеп итү өчен оригиналь тел-стиль чаралары эзләп азапланунын кайчак кирәге дә юк. Ә инде факт турында

сөйләгәндә кызыклы микрообразлар /мәсәлән, чагыштыру/, композицион алымнар табасың икән, язмаң өстәмә тәэсир көченә ия була дигән сүз.

Хәбәрнең баш-исемен сайлау зур осталык таләп итә. Журналист әсәренең баш исемнәрен өйрәнүгә багышланган махсус фәнни хезмәтләрдә аның атау, хәбәр итү, бәя бирү, коммуникатив, мөрәҗәгать итү, кызыксындыру, экспрессив, бүлү, реклам һ.б. функцияләрен аерып чыгаралар[8].

Күзәтүләр күрсәткәнчә, татар газеталарындагы хәбәрләрдә атау функциясе башкаручы исемнәр аеруча еш эшкә җигелә. Бу очракта баш исеменә бөтен текстның кыскача эчтәлеге чыга: *"Сөембикә"не туган көне белән котлау (Ш.К.) "Северсталь" - "Ак Барс" - 1 : 1 (Шунда ук). Сентябрь аенда 26 градус эсселек көтелә (Т.я.)* һ.б.

Баш исеме, теманы белдермичә, вакыйганың урынын гына да атарга мөмкин: *"Каенкай"да кунаклар (С.), Агыйделнең яңа агышы (Т.я.).*

Кайчак баш исеме гомуми (интегратив) теманы белдереп килә: *Вена татар артистларын сәламли (М.?.), Без Анапада булдык (С.).*

Атау функциясе үтәүче баш исемнәренең нинди төре кулланылуга карамастан, калыплашкан төзелешле текстларда, кагыйдә буларак, тема тулаем беренче җөмләдә хәбәр ителә һәм аннан соңгыларында тәгаенләнә.

Шул ук вакытта хәбәрдә баш-исеменең экспрессив функция үти торганнары да кулланыла ала. Баш-исеменең мондый төренә автор укучыны кызыксындыру, аның игътибарын җәлеп итү максатында мөрәҗәгать итә. Мәсәлән, "Ватаным Татарстан" газетасында "Су астында хазинә бар" дигән баш-исем астында аңлатмалы хәбәр чыкты. Газета укучы бу хәбәрне, билгеле инде, су астыннан табылган ниндидер кыйммәтле борынгы хәзинә турында сенсацион яңалык ишетү нияте белән укырга керешә. Тик язмадан бу

---

[8] Винокур Г.О. Күрсәтелгән хезмәт.; Костомаров В.Г. Күрсәтелгән хезмәт.; Лазарева Э.А., Червякова Т.Б. Заголовок в местных газетах // Язык и композиция газетного текста: теория и практика. - Свердловск, 1987. - С.158-171 һ.б..

"хәзинә"нең су төбеннән алына торган органик ашлама - сапропель булуы ачыклана. Сапропель авыл хужалыгы хөзмәтчәннәре өчен чынлап та кыйммәтле табылдык икән.

Баш-исем сыйфатында тойгылы, өндәү һәм сорау җөмләләр, ким һәм кире җөмләләр, фразеологизмнар, әйтемнәр, микрообразлар, төрле модаль формалар куллану да аның хисси тәэсирен көчәйтә.

Контроль сораулар:

1. Хәбәр жанрының төп функциясе нидән гыйбарәт?
2. Хәбәр алдына куела торган төп таләпләрне атагыз.
3. Хәбәрнең нинди төрләрен беләсез? Алар бер-берсеннән нинди сыйфатлары белән аерылып торалар?
4. Хәбәрда фактнын роле турында сөйләгез.
5. Бу жанр нинди тел-стиль үзенчәлекләренә ия?

Биремнәр:

1. Татарча газетадагы хәбәрләр туплап бирелә торган берәр рубрикага күзәтү ясагыз.
2. Өлкәннәр һәм балалар газетасында чыккан бернича хәбәрне үзара чагыштырып анализлагыз.
3. Бер үк вакыйга яки факт турында хроника хәбәр һәм аңлатмалы хәбәр язгыз.

Хәбәрдә журналист бәясе

Бәя - журналист иҗатындагы мөһим категорияләрнең берсе. Ул “журналистның фактка яки фактлар суммасына уңай яки тискәре

мөнәсәбәтен характерлый”[9]. Журналист бәясе укучыга чынбарлыкның гаять катлаулы һәм күпкырлы күренешләрен дөрес кабул итәргә булыша.

Бер караганда, хәбәри жанрларга караучы текстларда, бигрәк тә аларның калыплашканнарында бәя бөтенләй булмаска тиеш кебек, чөнки объективлыкка һәм битараф иншалауга омтылыш — аларның мөһим асыл сыйфаты. Ләкин, беренчедән, теге яки бу фактны журналист тексты өчен нигез итеп алу үзе үк бу фактка битараф булмауны күрсәтә. Икенчедән, теләсә кайсы “коры” хәбәрдә дә яңалыкка уңай яисә тискәре мөнәсәбәтне белдерү — безнең газеталар өчен традицион күренеш.

Сиксәненче еллар азагына кадәр, вакытлы матбугат билгеле бер идеологияне генә үткәрүче чара булган чорда, хәбәри жанрлар, теге яки бу яңалыкны укучыга җиткереп кенә калмыйча, аңа һәрвакыт диярлек бәя дә биреп баралар иде. Бу бәя, әлбәттә, аерым бер журналистныкы, хәтта газетаныкы да түгел, ә идарә итүче партия мәнфәгатьләрен чагылдыручы коллектив бәя. Чөнки барлык матбугат — шул партиянеке.

“Социалистик Татарстан” газетасының 1961 елгы 19 март санындагы бер хәбәргә күз салыйк ?ле:

Биләр районы беренче квартал планын үтәү өчен дәүләткә көн саен 35,7 тонна сөт тапшырырга тиеш. Фактта ул 10-15 тонна сөт сата. КПСС райкомы секретаре Никитин, район Советы башкарма комитеты председателе Әхмәтов иптәшләр, сез моңа ничек карыйсыз?

Монда язма авторының позициясе партия өлкә комитеты куйган таләпләрдән чыгып билгеләнә. Чынлыкта район җитәкчеләрен журналист түгел, барлык дилбегәләрне үз кулында тотучы партия “утлы табада кыздыра”. Халыкара темага хәбәрләрдә мондый күмәк бәя аеруча ачык күзгә бәрелә:

Америкадан ГФР территориясенә АКШның Хунсрюккадагы хәрби базасында урнаштырылачак берничә ракета китерелде. Шулай итеп Американың <u>идарәче даирәләре</u> үзләренең <u>еракка киткән мәкерле планнарын</u>

[9] Горохов В.М. Основы журналистского мастерства. — М., 1989. — 88 б.

тормышка ашыру өчен чираттагы адымнарын ясадылар (Социалистик Татарстан, алга таба С..Т.).

Асларына сызылган сүзләр фактка бәя бирүгә хезмәт итәләр. Алар — үз чорында идеологик дошманнарга тискәре мөнәсәбәт белдерү өчен хезмәт итә торган калыплашкан тел чаралары, идеологик штамплар булган.

Идеологик кыйммәтләрне формалаштырудагы көндәлек эшчәнлек нәтиҗәсендә социализм чорында газеталарыбызда идеологик бәя мәгънәсенә ия булган үзенчәлекле лексик катлам барлыкка килде. Заманында Г.Я.Солганик аны газетаның сүзлек составындагы “иң мөһим разряд” дип билгеләгән иде[10]. Бу лексик төркемнең барлыкка килүе теләсә кайсы тел өчен хас булган икенчел номинация күренеше белән бәйле[11]. Күп кенә исемнәр, татар теле системасында стилистик яктан нейтраль, бәясез булган хәлдә, газетада яктыртыла торган охшаш ситуацияләрдә даими рәвештә икенчел мәгънәдә кулланылып, төрле стилистик төсмерләргә ия булган яңа мәгънәләр алалар. И.М.Низамов аларны газетизм дип билгели [12]. Сиксәненче еллар азагына татар вакытлы матбугаты телендә идеологик характердагы газетизмнар системасы формалашты. Икенче мәгънәсе уңай бәя булган мондый сүзләргә *үр, җимеш, офык, маяк* кебекләрне, тискәре мәгънәлеләренә *җанвар, калдык, богау* һ.б. сүзләрне кертергә мөмкин.

Газетаның оператив һәм көндәлек характеры белән бәйле рәвештә уңай яки тискәре бәягә ия булган калып гыйбарәләр дә барлыкка килә. Аларның кайберләре, артык еш кулланылып, штампларга да әйләнеп китә. Болары — газета телен тискәре яктан характерлый торган элементлар. Әйтик, шул ук сиксәненче еллар азагына түбәндәге штамплар аеруча ешаеп китте: *удар хезмәт, юбилей алды хезмәт вахтасы,*

[10] Солганик Г.Я. Лексика газеты... - 36 б.

[11] Уфимцева А.А. Лексическая номинация (первичная нейтральная) // Языковая номинация: Общие вопросы. - М., 1977. - 45 б.

[12] Низамов И.М. Матбугатның тәэсирле сүзе... - 66 б.

ярышка тон бирү, алдынгы тәҗрибә уртаклашу`, лаеклы өлеш кертү, үр яулау һ.б.

Калыплашкан гыйбарәләр — теләсә кайсы чор газеталары өчен хас күренеш. “Бүгенге тормыштагы фактлар, ситуацияләр һәм аларга бирелә торган социаль-сәяси бәянең даими үзгәреп торуы аркасында аларны белдерүче тел чаралары да гел үзгәреп, калыплашып тора”[13]. Идеологик бәяле калып гыйбарәләр әкренләп газета битләреннән югалды. Шул ук вакытта хәзерге газеталарда көн кадагына суга торган яңа гыйбарәләр формалышты: *кайнар нокталар, демократия җилләре, хосусыйлаштыру җимешләре, милләт хадиме, базарга керү, базар мөнәсәбәтләре* һ.б.

Газетизмнар һәм калып гыйбарәләр, кайсы чорда кулланылуларына карамастан, коллектив бәя бирүгә хезмәт итәләр, ягъни аларда хәбәр ителә торган фактка карата субъектив, шәхси бәя түгел, ә җәмгыятьнең, җәмгыятьтәге билгеле бер социаль төркемнең, катламның, коллективның бәясе белдерелә.

Туксанынчы еллар башына кадәр калыплашкан газета текстларында әнә шундый коллектив бәя өстенлек итте, “чиста”, ягъни бәясез хәбәрләргә урын бирелмәде диярлек. Ә инде журналистның шәхси бәясенә урын бөтенләй булмады.

Соңгы бер-ике дистә елда вакытлы матбугатта тематик үзгәрешләр белән бергә “бәя” категориясе дә үзгәреш кичерде. Хәбәр жанрында бу категориягә бәйле ике капма-каршы тенденция барлыкка килде. Беренчесе — текстның тулы нейтральлегенә, бәясезлегенә ирешергә тырышу, икенчесе — текстта бәя булган очракта, аның субъективлыгына, шәхсиләштерелүенә омтылыш.

Хәзер журналист, югарыда искә алынган социалистик идеология хакимлеге чорыннан аермалы буларак, иҗтимагый-сәяси темага текстларда да үзенең шәхси бәясен иркен белдерә ала. Бу бәя җәмгыятьтә формалашкан традицион фикерләрдән генә түгел, хәтта матбугат

[13] Костомаров В.Г. Күрсәтелгән хезмәт, — 190 б.

органының үз позицияләреннән дә аерылып торырга мөмкин. Бер үк вакыйгага төрле журналистлар һәм төрле басма органнар тарафыннан төрле бәя бирү очраклары да еш очрый хәзер.

Күзәтүләр шуны дәлилли, “бәя” категориясе өчен характерлы ике капма-каршы тенденция гасыр башында нәшер ителгән татар газеталары өчен дә хас булган һәм бүген яңа бер сыйфат баскычында кабатлана гына икән. Г.Тукай иҗатында аларның икесе дә очрый. Аның “Фикер” газетасында чыккан түбәндәге хәбәрләренә күз салыйк:

Баку хәбәре. Сәгать җидедә татарлар урамында мөһәндис Коган таланган. Тагын бер урамда нәмәгълүм урыс үтерелгән. Шимахинкә дигән җирдә бер мөселман нәгыше табылган. Катилләр хәзергәчә табылмаган.

Казанда конфисковать итүләр. Казанда 14 сентябрьдә “Волжский курьер” вә “Бәянелхак” гәзитләре конфисковать ителгәннәр.

Троицк. Төнлә ат кәмитеннән кайтканда, Яушевларның ике приказчиклары үтерелеп, 500 сум акчаларын алганнар.

Бу текстларда авторның вакыйгага мөнәсәбәте бөтенләй сизелми диярлек. Чөнки алар башлыча конкрет-номинатив лексикадан гына тора.

Шул ук газетада чыккан икенче бер хроника-хәбәр текстында, киресенчә, Тукайның шәхси бәясе ярылып ята:

Чистай. Чистайда элек тә зур бинаы мәдрәсә бар иде. Бу ел янә сигез меңгә төшереп мәдрәсә салдылар. Икесендә дә укытырлык мөгаллимнәр юк. Мөгаллимнәргә акча юк. Мәдрәсә стеналарын арттырганчы, укытуны, укытучыларны арттырырга кирәк. Безнең хәзрәтләр: “Ишәккә баш булсаң да, баш бул”, дигән мәкальне муафикъ табып, һәркайсы үзе баш мөдәррис булыр өчен мәдрәсә арттыралар, канәгать итәрлек укыту юк.

Әлеге мисалда бәя бирү функциясен мәкаль, фигыльнең модаль формасы, бәя семантикасына ия булган лексик чаралар һ.б. үти.

Хисап жанры

Хисап теләсә нинди вакыйга турында түгел, ә, кагыйдә буларак, сөйләшүгә корылган вакыйга (съезд, конференция, корылтай, җыелыш, киңәшмә, утырыш, митинг, пресс-конференция һ.б.) турында сөйли.

Хисап текстының хәбәр кебек җыйнаклары да, шакгый күләмлеләре дә очрый. Монысы инде куелган максатка бәйле. Әгәр журналист алдына вакыйганың иң мөһим этапларын гына оператив рәвештә хәбәр итү максаты куела икән, ул кыска хисап төренә мөрәҗәгать итәргә тиеш.

Кыска хисап тексты бер яки берничә абзацтан тора:

Күңелдә милләт язмышы

Нефтьчеләрнең Муса Җәлил исемендәге мәдәният йортында поселокта һәм районыбызда яшәүче татар милләте вәкилләренең җыелышы үткәрелде. Аны Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Б.Гарипов алып барды.

Җыелышта татар мәдәнияты, әдәбияты, халкыбызның тарихы, дине, милләтебез, туган телебез язмышы, район узганда мәчет төзү турында сүз барды.

Инициатив группа исеменнән район газетасының бүлек мөдире С.Әхматҗанов Татар иҗтимагый үзәгенең Баулы бүлекчәсен оештыру мәсьәләсен күтәреп чыкты. Бүлекчәнең унҗиде кешедән торган идарәсе сайланды. Соңыннан мәдәният йорты үзешчәннәренең концерты булды. (В.Т.)

Бу язмада вакыйганың булуы икърар ителә һәм аның иң мөһим мизгелләре генә санап чыгыла. Димәк, бу очракта журналист өчен дә, укучы өчен дә вакыйганың булу факты мөһим. Шуңа күрә җыелышның нинди шартларда узуы, чыгышларның тулы эчтәлеге игътибардан читтә калган.

Аерым бер вакыйга җәмгыятебез тормышында никадәр зуррак әһәмияткә ия булса, матбугат битләрендә ул шулкадәр киңрәк якгыртыла. Бу очракта инде газета укучыны кыска хисап кына канәгатьләндерә алмый,

киңәйтелгән хисапка мөрәҗәгать итәргә туры килә. Хисапның киңәйтелгән төрендә сүз вакыйга һәм аның асылы турында гына бармый, бу вакыйганың кайбер мизгелләре киңрәк яктыртыла, бигрәк тә мөһим чыгышлар яки алардан өзекләр китерелә. Парламент утырышы кебек мөһим вакыйгалардан язылган хисапларда, әйтик, еш кына төп чыгышлар шактый тулы, хәтта тулаем китерелә. Мондый текстта ике сөйләм иясен, димәк, ике сөйләм планын аерып карарга мөмкин: вакыйга турында сөйләү планы һәм вакыйга эчендә сөйләү планы.

Киңәйтелгән хисаплар беренче татар газеталарында ук шактый күп очрый, чөнки XX гасыр башы, иҗтимагый тормыш кайнап торган чор буларак, төрле җыелыш, съезд, митингларга бай булган. Мисал өчен “Фикер” газетасының 1906 елгы 6 октябрь санындагы “Казан” миһманханәсендә мәҗлес” дигән язмага мөрәҗәгать итик. Аның авторы — Габдулла Тукай. Текст вакыйганың үзен, урынын һәм вакытын атаучы калып җөмлә белән ачылып китә:

“Казан” миһманханәсендә 1 нче октябрьдә кич сәгать алтыда дарелмөгаллимин ачу хосусындагы җәмгыятьнең мәҗлесе ачылды.

Алга таба автор вакыйганың төп этапларын санауга һәм аларны тәгаенләштерүгә күчә. Башта ул кыек сөйләм аша беренче чыгышның төп фикерләрен санап чыга:

Иң әүвәл мөхәррир Камил әфәнде Мотыйгый аякка торып, бу җәмгыятьнең ни өчен ясалганын вә моннан киләчәктә нинди файдалар туачакларын, бу хәерле эшкә кулдан килгәнчә һәр мөселманга тырышу фарызлыгын, бу җәмгыятьнең файдасына әүвәл башлап үзенең 1000 тәңкә бирәчәген һәм Мортаза байның 20 мең тәңкә бирергә вәгъдә кыйлганлыгы мәсмугы улдыгын гаять ачык вә әсәрле сурәттә бәян вә ифадә итте.

Вакыйгада чыгыш ясаучы калган кешеләрнең фикерләре туры сөйләм ярдәмендә бирелә:

Гомәр Хөсәенов: “Вә гатсәмбу бәхбиллаха җәмига” аяте кәримәсе илә “Әлмөэминүн кялябәйниян бишт бәгъзеһөм бәгъзан” хәдисен укып, соңра

тәфсир итеп: “Бу җәмгыятькә без аерылыр өчен килмәдек, һәрничек берләшергә, барчамыз бер сүзне сөйләргә кирәк”, - диде.

Фатих Шәрипов: “Безгә шул борынгы мәдрәсәләр дә җитәр, безгә шулардан башка мәдрәсә кирәкми”, -диде.

Габдулла Тукаев: “Юк, Фатих абзый! Безнең ул мәдрәсәләремез генә җитми, башка милләтләрдәге кеби, безгә дә 3-4 этажлы мәдрәсәләр кирәк...

Шулай итеп автор биредә объектив һәм битараф күзәтүче ролен башкара. Аның бу вакыйгага мөнәсәбәте бары тик текст азагында китерелгән бердәнбер комментарийда гына чагыла:

Мәҗлес бик тәртипле генә, тын гына бер сурәттә үтте, председатель җанәбләре икенче мәҗлесне 6 нчы октябрь, җомга көн сәгать кичке 7 дә булырга тәгаен итте, халык та разый булдылар. Аллаһе тәгалә шуның кеби җыелышларны тагы насыйп вә мөяссәр итсен.

Хисап жанрының тагын бер мөһим төре бар. Ул - стенографик хисап. Анда, алдагы төрләрдән аермалы буларак, вакыйга һәм аның агышы тулысы белән яктыртыла, барлык чыгышлар башыннан азагына кадәр сүзе сүзгә күчереп бастырыла.

Сессия, конференция, җыелыш һ.б. шуңа охшаш вакыйга турында язарга җыенган журналист кайвакыт бу вакыйганың бер генә ягына игътибар итә, төп игътибарны вакыйганың барышына яки барлык чыгышларның эчтәлегенә түгел, ә конкрет бер темага юнәлтә. Бу - тематик хисап. Әйтик, шәһәр Советы сессиясендә берничә төрле мәсьәлә арасында яшьләрнең ялын оештыру проблемасы да тикшерелә икән, яшьләр газетасы игътибарны соңгысына бирәчәк. Журналист төп докладны да, чыгышларны да үзе яктырта торган тема күзлегеннән чыгып тыңлый, кирәкле өлешләрен сайлап ала. Шулай булгач, вакыйганың башка өлешләре тематик хисаптан төшеп калачак.

Проблемалы хисапта да вакыйга тулысы белән чагылыш тапмый, нинди да булса мөһим проблеманы-яктырту өчен бер сәбәп кенә булып тора. Автор чыгышларда әйтелгән аерым фикерләргә анализ ясый, аларга бәя бирә, үзе дә мөһим мәсьәләләрне хәл итү юлларын эзли, уйлана. Хисапның бу төрендә

эшләүче журналист, билгеле, яктыртыла торган проблема буенча аеруча хәбәрдар булырга тиеш. Хисапның бу төрен журналистика теоретигы А.Тертычный аналитик жанрлар төркеме кысаларында тикшерә.

Хисапның төренә бәйле рәвештә язмаларда автор индивидуальлегенең роле төрле дәрәҗәдә чагылырга мөмкин. Мәсәлән, стенографик хисапта ул юк диярлек. Икенче төрле әйтсәк, бу төрдәге язмаларны эшләүче журналистның төп бурычы - әзер стенографик материалны, дөреслеген тикшереп һәм логик эзлеклелеген саклап (доклад һәм чыгышларның тәртип санын да үзгәртмичә), газета бите өчен әзерләү. Монда иҗадилыкка да, автор бәяләренә дә урын юк.

Бу жанрның башка төрләрендә исә автор индивидуальлеге киңрәк чагылыш таба. Дөрес, аларда ул рәсмилек дәрәҗәсенә бик нык бәйле. Әгәр автор киңәйтелгән хисапта вакыйганың төп мизгелләрен, чыгышларның эчтәлеген мөмкин кадәр объектив, шул ук вакытта нейтраль позициядән чыгып җиткерергә омгыла икән, рәсмилек дәрәҗәсе шактый югары була. Биредә авторның уй-кичерешләре һәм эмоцияләре катнашырга тиеш түгел. Тик андый материалларда да автор позициясе күренми калмый. Иң беренче чиратта ул авторның вакыйга барышында теге яки бу моментка, аерым чыгышларга ныграк игътибар итүендә күренә.

Автор индивидуальлеген газета укучы рәсми булмаган хисапта аеруча нык тоя. Вакыйга үзе никадәр рәсми булмасын, журналист аңа үз күзлегеннән чыгып бәя бирергә, шушы вакыйгадан алган хисләре белән уртаклашырга да хокуклы ич.

Журналистның актив позициясен ачык белдерү проблемалы хисапта аеруча әһәмиятле. Мондый материалларда автор вакыйганың логик эзлеклелеген сакламаска да, чыгышларның эчтәлеген үз сүзләре белән генә әйтергә яки аларның кайберләренә бөтенләй игътибар бирмәска дә хаклы. Чөнки беренче планга конкрет проблема чыга. Текстта төпле анализга да, эмоциональ бәяләргә дә урын бирелә.

Хисап жанрында иҗат итү - шактый үзенчәлекле эш. Хисап - вакыйгада катнашып, аның эчтәлеген сөйләп чыгу гына түгел ул. Иң башта журналист

теманы дөрес сайларга тиеш. Ул актуаль дә, журналистның "теше үтәрлек" тә булсын. Мәдәният проблемалары белән шөгыльләнүче хәбәрче авыл хуҗалыгы мәсьәләләренә багышланган киңәшмәгә бармас.

Вакыйгага алдан әзерләнү кирәк: яктыртыла торган темага, проблемага бәйле әдәбиятны, газета-журнал материалларын күздән кичерү файдалы. Вакыйга башланганчы, анда катнашучылар белән алдан очрашулар һәм фикер алышулар да комачау итми. Кыскасы, автор, вакыйганы пассив күзәтүче булып кына калмыйча, аның эчендә кайнаса, уңышка ирешә. Шул ук вакытта игътибарны төп вакыйгадан читкә юнәлтергә ярамый. Чөнки анда катнашучыларның (чыгыш ясаучыларның) исем-фамилияләре дә, вазифалары да, чыгышларның төп эчтәлеге дә түгәл теркәлеп барырга тиеш. Вакыйга төгәлләнгәннән соң бу мәгълүматларны тагын бер кабат тикшерү зарур, чыгышларның бер нәсхәсен, алдан килешү буенча, үзеңә ала алсаң, тагын да яхшы. Диктофон яки башка техник чаралар куллану шулай ук максатка ярашлы. Чараны оештыручының интернет челтәрендәге сайтына кереп тә күп кенә алмәгълүмат үзләштерергә мөмкин.

Хисапта композиция һәм стиль чараларын дөрес сайлап алу мөһим. Стенографак хисапта, кыска хисапларның күпчелегендә текстның композициясе вакыйга эзлеклелеге нигезендә төзелә. Авторның роле арта барган саен композиция дә катлаулана, вакыйга эзлеклелеге сакланмый башлый. Югарыда китерелгән мисалда, әйтик, текст авторның кичерешләрен тасвирлау белән башланып киткән иде.

Проблемалы хисапта композиция аеруча ирекле, авторның шәхси фикерләвенә бәйле.

Бу жанрның тел үзенчәлекләре турында сөйләгәндә, аның рәсми стильгә якын торуына игътибар итәләр. Чынлап та, күпчелек хисаплар рәсми стиль әйләнмәләренә, лексикасына һ. б. чараларга бай була. Бу шуның белән аңлатыла: яктыртыла торган вакыйгада (мәсәлән, жыелышта) кешеләрнең үзара аралашуы рәсми тонда бара. Тик шулай да, автор, үзенең күзәтүләре, фикерләре, хис-кичерешләре турында сөйләгәндә, экспрессив төсмергә ия

булган сүзләргә дә, грамматик чараларга да, микрообразларга да мөрәҗәгать итә ала. Димәк, хисапның бик рәсми булмаган төрләрендә һәм матур әдәбият, һәм жанлы сөйләм өлкәләренә хас тел-стиль чараларын да файдаланырга мөмкин. Хисап авторының журналист буларак осталыгы шунда күренә дә инде: беренче карашка кызыксыз һәм ялыктыргыч тоелган вакыйга (ләкин мөһим вакыйга) турында да газета укучыны кызыксындырырлык итеп сөйләп бирә алу.

Контроль сораулар:

1. Хисап жанрының төп функция-бурычлары нинди ?
2. Хисапны? нинди төрләре бар һәм аларның үзенчәлекләре нидән гыйбарәт?
3. Бу жанрда иҗат итүнең үзенчәлекле яклары турында сөйләгез.
4. Хисап жанрына хас композиция һәм тел-стиль чараларын атагыз.

Биремнәр:

1. "Ватаным Татарстан" газетасында басылып чыккан "парламент хәбәрләре"нә күзәтү ясагыз.
2. Нинди дә булса вакыйгадан тематик хисап языгыз.

Репортаж жанры

"Репортаж" сүзенең нигезендә латин сүзе ята һәм ул "хәбәр итү" дигәнне аңлата. Репортаж жанры да, хисап кебек үк, җәмгыять тормышындагы мөһим вакыйгаларны якгырту максатында кулланыла. Репортажның эчтәлеген тәшкил итүче вакыйга, кагыйдә буларак, сөйләшүгә генә корылмый, ә эш-хәрәкәткә, динамикага бай була. Бу жанрдагы материаллар, мәсәлән, спорт ярышыннан, завод яки фабрика цехыннан, иген басуыннан язылырга мөмкин. Вакыйганың яна гына узуы, газета укучы өчен яңалык булуы мөһим. Репортажның тагын бер үзенчәлекле билгесе: автор вакыйга турында үз күзлеге, үз кичерешләре аша

сөйләргә, укучы аны тулысынча күзалларлык итеп тасвирлап бирергә омтыла. Нәтиҗәдә, газета укучы да журналист белән бергә вакыйганың шаһитына әверелгән кебек була.

Журналистикадагы иң үзенчәлекле жанрларның берсе булган репортаж шактый бай тарихка ия. Узган гасыр башы газеталарында репортаж жанрында актив эшләгән классикларыбыздан Габдулла Тукайны аерып күрсәтергә мөмкин. Кайнар эзләрдән язучы оператив репортер буларак Хади Килдебәков та танылган. 1917 елгы шанлы вакыйгалар чорында һәм аннан соңрак хатын-кыз журналистларыбыздан Абруй Сәйфи үзенчәлекле репортаж үрнәкләре иҗат иткән. Бөек Ватан сугышы елларында фронт репортерлары буларак танылган язучы-журналистлар Г.Кутуй, М.?әлил, Ш.Мөдәррис, Г.Әпсәләмов, М.Максуд, А. Шамов, Р.Ишморат һәм башкалар матбугатыбыз тарихында тирән эз калдырды. Сугыштан соңгы елларда, узган гасыр азагында һәм хәзер дә бу жанрның танылган осталары күп булды һәм бар.

Репортаж текстының төзелеш үзенчәлекләрен карап үтик. Бу үзенчәлекләр жанрның үзенчәлекле вазыйфалары белән билгеләнә.

Репортажның эчтәлеген тәшкил итүче вакыйга, кагыйдә буларак, эш-хәрәкәткә, динамикага бай була. Вакыйганың әле яңа гына узган булуы зур әһәмияткә ия. Репортажның тагын бер үзенчәлекле билгесе: автор вакыйга турында үз күзлеге, үз кичерешләре аша сөйләргә, укучы аны тулысынча күзалларлык итеп тасвирлап бирергә омтыла. Нәтиҗәдә укучы да журналист белән бергә вакыйганың шаһитына әверелгән кебек була. Шуңа күрә, репортаж — укучының күзләре һәм колаклары, дип тә әйтәләр.

Репортаж текстында вакыйгаларның реаль вакыт эзлеклелеге мөмкин кадәр саклап чагылдырыла. Шуңа күрә бу жанрдагы текстлар өчен проспекция һәм ретроспекция, автор кичерешләре, тирән һәм системалы анализ хас түгел.

Репортажның төрләре берничә. Иң еш очраучысы – вакыйгалы репортаж. Аңлашылганча, жанрның бу төре оператив яктыртуны таләп иткән мөһим вакыйгага багышлана. Ләкин инде максат, хәбәрнекеннән аермалы буларак, вакыйга турында оператив хәбәр итү генә түгел, аны тасвирлап, детальләштөреп бирү, вакыйгага карата анда катнашучыларның һәм авторның мөнәсәбәтен белдерү, вакыйганың сәбәпләрен ачыкларга яки нәтиҗәләрен билгеләргә омтылу һ.б. Димәк, вакыйгалы репортажда мәгълүмат бирү белән генә чикләнмичә, фактларга анализ ясау да кирәк. Бу жанрның башка төрләре анализга тагын да баерак, чөнки аларда вакыйга - нинди дә булса проблемага игътибарны юнәлтү өчен бер сәбәпче генә.

Тематик репортажның үзәгендә алдан планлаштырылган тема ята. Әлбәттә, репортажның бу төре да берәр төрле вакыйгага нигезләнеп языла. Ләкин, югаруда әйтелгәнчә, төп максат вакыйганы яктырту түгел, ә шушы вакыйгага бәйле мөһим теманы ачып бирү. Журналист гел яңа, кызыклы, гадәттән тыш вакыйгалар гына эзләп йөри алмый. Көндәлек тормыштан да репортаж язарлык темаларны күпләп табарга мөмкин. Игътибар һәм күзәтүчәнлек кенә кирәк. Тәҗрибәле журналист Мирхәт Хөснимәрдәновның иҗатына күз салсак, аның тормышыбыздагы гадәти күренешләрдән, үзенең очраклы очрашуларыннан да кызыклы репортажлар язуын күрербез. Бу авторның завод-фабрикалардан, фәнни лабораторияләрдән, музей-театрлардан язган тематик репортажлары һәм репортаж цикллары меңләгән укучының күңелен яулагандыр.

Тематик репортаж оператив булмаска да мөмкин. Ләкин шушы жанр өчен хас булган калган барлык сыйфатларны ул үзендә саклый.

Проблемалы репортажда да оперативлык ул кадәр мөһим түгел. Мондый төрдәге язмада беренче планга авторның эзләнүләре, уйланулары һәм анализы чыга. Вакыйгага таяну, авторның "мин"ен ассызыклау әһәмиятле проблемага багышланган репортажда да саклана, билгеле.

Бу жанрның тәнкыйди репортаж дигән төрен дә аерып чыгаралар. Монысы газеталарыбызда сирәгрәк очрый.

Репортаж жанрындагы язманы композицион яктган оештыруда авторның мөмкинлекләре чикләнмәгән. Шулай да бу жанрның композициясе өчен хас булган кайбер үзенчәлекле билгеләрне аерып алырга мөмкин. Репортаж, нигездә, вакыйганын эзлеклелеге буенча корылса да, композициядә бу эзлеклелектән читкә тайпылышлар да еш очрый. Мәсәлән, автор язманы үзе яктыртырга алынган вакыйганын иң кызыклы мизгеленнән башлап җибәрергә мөмкин:

Бозда туп тәгәри. Аны кулларына кәкре башлы кәшәкәләр тоткан тимераяклы... кызлар куа... (Ш.К.)

Мондый башлам куллану газета укучының игътибарын җәлеп итәргә, артык фәлсәфәгә бирелмичә, вакыйганың эченә кереп китәргә мөмкинлек бирә. Тасвирлаулар, лирик чигенеш рәвешендәге фикер йөртүләр, көчкенә диалоглар һ.б. - репортаж текстының үзенчәлеген билгеләүче мөһим композицион элементлар. Шунысы да игътибарга лаек, бу жанрда композициянең аерым кисәкләре озын һәм эчпошыргыч булмаска тиеш. Алар еш алышынып тора. Шулай итеп, төрле кадрлар чиратлашып торган фильмдагы кебек, сөйләү планнары еш алышына һәм вакыйганың динамик характеры текстка да күчә.

Вакыт һәм урынны ассызыклап бирү — репортаж текстының иң үзенчәлекле билгеләреннән берсе. Әйткәнебезчә, бу жанрдагы текст еш кына тасвирлаудан башаланып китә. Шуның белән укучы баштан ук вакыйга вакытына “күчереп куела”.

Хәзерге заман вакытын, вакыйга мизгелен ассызыклаучы тагын бер композицион берәмлек — диалог. Аны репортажда монологик сөйләмне җанландыру, динамиканы көчәйтү, вакыйга узган урынны тулырак күз алдына китереп бастыру өчен кулланалар. Диалогта һәрвакыт аралашу мизгеле дә сиземләнә һәм ул репортажда, төп вакыйга вакыты белән тәңгәл килеп, аны ассызыклауга хезмәт итә.

Хәзерге репортажларда, анализга омтылышның күпкә көчәюе нәтиҗәсендә, текстка өстәмә вакыт планнары да күпләп килеп керергә мөмкин. Бу бигрәк тә төп вакыйгаларның әһәмиятен ассызыклау өчен аны

башка факт һәм вакыйгалар фонында сурәтләргә кирәк булганда эшләнә. Әйтик, вакыйганың әһәмиятен дөрес аңлау өчен үткәнгә күз салу зарур була. Шулай да репортаж төрендәге текстларда төп вакыйганы белдермәгән барлык өстәмә вакыт планнары, төп вакыйга планына буйсынып, аңа ияреп кенә килә алалар.

Узган гасырның 20 нче елларында репортаж остасы булып танылган Абруй Сәйфи текстларында вакыт һәм урынны ассызыклау тәҗрибәсе игътибарга лаек. Аның "Аваз" газетасында чыккан "Казан хатыннарына һөҗүм" (1917, 16 авг.) дигән язмасына күз салыйк:

11 августта мәйданда була башлаган митингта кыйнала башлавым ошбу рәвешчә: мин мәйданга килгәндә, мәйдан халык белән тулган, рәшәткә буйларында аз-маз хатыннар күренә, мөнбәрдә Мөхәммәтҗан Хафиз бик кызу нотык сөйли. Мин мөнбәр янына ук барып, эшне тикшерә башладым. Ләкин һич нәрсә аңлап булмый, халык ифрат болгана, бер читтә аңсыз солдатлар, аларга кушылган печән базары кешеләре. Мине күрүгә "хатыннар долой, хатыннар долой" дигән тавыш күтәрелде.

"Долой" тавышлары соңында бөтен мәйдан халкы хатыннарга һөҗүм иттеләр, мәйдан тирәсендәге хатыннарның күбесе кача башлады, бер төркем аларны куа китте, икенче бер өлеше минем тирәдә дә минем өскә җикеренәләр иде. Шулай да берничә минут тартыштым, теге күтәрелгән йодрыклар да миңа йомшак-йомшак бәргәләп алдылар.

Ахырында үзебезнең бюро әгъзалары берничә хатын мине ялынып тартып алып чыктылар. Ирексез хатыннар арасына барып кушылдым. Зур корсаклы байгуралар аннан да кудылар. Менә озак та үтми халык арасыннан ике милиционер бер адәмне өстерәп алып чыгып килә. Без аның тирәсенә җыелып, аларны туктаттык. Ул Ярулла Хәйруллин дигән бер ачык фикерле адәм икән, безне химая итеп сөйләгән сүзе өчен изеп ташлап кыйнаганнар да, частька илт, дип, милиционерлар кулына биреп җибәргәннәр.

Бу өзектә вакыт һәм вакыйганың урыны укучының күз алдына бик ачык итеп китереп бастырыла.

Революция чорындагы һәм 20-30 еллардагы журналист хезмәтенең үзенчәлекләре, ул чордагы үзгәрешләр темпын чагылдыру ихтыяҗы аркасында репортаж текстлары гаять җанлы, хәрәкәтчән итеп оештырылган. Моның бер мисалы — танылган язучы һәм журналист Фатих Кәрим иҗаты. Аның “Кызыл Татарстан” газетасында басылып чыккан “Дуня Тимофееваның кызлары” дигән репортажына (1933, 1 май) күз салыйк:

Менә станок. Станокта - эшче кыз. Мин аның тарау станогында эшләгәнен карап торам да, ул кызны мәшһүр музыкантка охшатам. Бу кыз авыр эштә, станокта эшләүче гади эшче генә түгел, ул музыкант, станок музыканты ул.

Машинаның электр энергияләреннән көч алган частьлары пропеллер кебек кызу әйләнәләр, кәтүкләр зырылдап-зырылдап сүтеләләр, сүтеләләр дә, машинаның үзәгеннән үтеп орчыкларга уралалар. Әнә ике-өч кәтүкнеңнең җебе бетә. Станокта эшләүче хатын Зоха бушаган кәтүкләрне яшен кызулыгы белән суырып алып ящикка сала. Аннан яңа кәтүкләр тезеп куя. Ул ара да булмый, икенче кырыйда берничә кәтүкнең җебе өзелгән. Зоха аларны шундый кызулык белән төйнәп җибәрә, кулларын алар яныннан сирпеп үткәргән кебек кенә җибәрә. Әнә тагын станокта биш-алты орчык тулган, алмаштыруны көтәләр. Зоха, колачын җәеп, тагын станокка ташлана. Орчыкларны сыдырып алып ящикка сала. Кире ялт итеп станогына таба борылуына тагын берничә кәтүкнең җебе беткән. Зоха аларны тагын сыдырып алып яңаларын кидерә. Ул ара да булмый, шүреләр белән тулган ящигын җилкәсенә салып үлчәүгә йөгерә. Карагайлар арасында уйнаган яшен кебек, станоклар арасыннан үлчәүгә йөгерә ул.

Текстта вакыйганың җанлылыгын чагылдыру өчен күп төрле тел чаралары кулланылган.

Репортаж - газетадагы башка жанрларның үзенчәлекле сыйфатларын да үзенә тупларлык сәләткә ия катлаулы жанр. Анда хәбәр, хисап, интервью, макалә, очерк һ.б, жанрларның элементлары катнашырга мөмкин. Тик

функцияләре, мөмкинлекләре, буенча аны башка бернинди жанр белән да алыптырып булмый. Репортаж – күзәтче жанр. Ул вакыйга турында беренче булып, шул ук вакытта аны тасвирлап, газета укучы күзалларлык, бәя бирерлек дәрәҗәдә анлатып бирә.

Нинди генә темага язмасын, репортаж жанрында эшләүче журналист “вакыйгада катнашу эффекты” тудырырга омтыла. Язманың документальлеген һәм ышандыру көчен арттыручы бу эффект күп кенә үзенчәлекле алымнарны оста куллану нәтиҗәсендә барлыкка килә. Репортажда хикәяләү һәрчак автор исеменнән алып барыла, чөнки ул — вакыйганың шаһиты:

Кичә иртәнге сәгать унда Казанның Үзәк стадионы каршысыннан 30 лап автомобиль кузгалып китте. "Ретро-парад" шул була инде", - диештеләр моны күргән кешеләр. Автомобильләр парады, бөтен шәһәрне үтеп, М.Горький урамыннан Татарстан урамына борылды. Машиналар Г.Камал исемендәге татар театры каршысына килеп туктады. Аларны шундук кешеләр сырып алды (В.Т.).

Бу өзек әле яңа гына, сөйләүченең күз алдында булып узган хәлләр хакында эзлекле итеп хикәяли.

Репортаж жанрында эшләүнең технологиясе

Репортаж жанрының үзенчәлеген билгеләүче тел чараларыннан берсе - фигыльнең хәзерге заман формасы еш кулланылуы. Аны эшкә җигү нәтиҗәсендә вакыйгада катнашу тәэсире туа: газета укучы да журналист белән бергә вакыйганы күреп торган кебек була, чөнки бу форма сөйләү мизгеле белән эш-хәрәкәт мизгеленең тәңгәллеген ассызыклый.

Ниһаять, тантаналы минутлар - Үзәк стадиондагы мәдәни-спорт бәйрәмен ачу вакыты җитә. Фестиваль утын фехтование остасы, Олимпия чемпионы Наилә Гыйләҗева кабыза. Тантананы Казан шәһәре хакимияте

башлыгы Камил Исхаков кереш сүз белән ача. Һәм ул озын колгага Дәүләт флагын күтәрү өчен мәйданга татарча көрәш буенча күп тапкырлар Татарстан чемпионы Рәшит Сәмигуллинны чакыра. Менә бер-ике минуттан флаг, талгын җилдә җилфердәп, колга очында күренә. Шуны гына көткән кебек, югарыга төрле төстәге шарлар һәм ак күгәрченнәр күтәрелә (В.Т.).

Бу өзектә бер вакыт аралыгында һәм билгеле бер пространствода узган вакыйгалар эзлекле санап чыгыла; эш-хәрәкәт мизгеленең сөйләү вакытына туры килүе ассызыклана.

Фигыльнең хәзерге заман формасы ярдәмендә хикәяләү тудыру журналистика жанрлары арасыннан нәкъ менә репортаж өчен характерлы.

Хикәяләүнең динамик характеры шулай ук җөмләләрнең кыскалыгы нәтиҗәсендә дә ирешелә. Өстәлмә конструкцияләр рәвешендә җөмләләрнең аерым кисәкләрен җөмлә тышына чыгару әнә шуңа хезмәт итә:

Телефон чылтырый. Минут саен. АТС диярсең. Иван Петрович моңа шатлана. Кызыксына халык әлеге яңалык белән. Аның отышлы яклары барлыгына көннән-көн инана бара (В.Т.).

?өмләләрне шулай бүлеп бирү сөйләмнең динамикасын арттыру белән бергә аңа сөйләшү төсмере дә өсти.

Репортаж авторы үзенең вакыйгада катнашуын ачыктан-ачык белдергәнгә күрә, хикәяләү төрендәге синтаксик бөтеннәр фигыльнең беренче зат формасына һәм беренче заттагы зат алмашлыкларына бай була:

А.Кузьминга игътибар итәм. Сизеп торам - ул дулкынлана. Александр - минем белгән кешем. Аның белән тантана башланганчы танышып өлгергән идем. Кай ягы беләндер күңелне биләп алды ул минем (С.Т.).

Әйтелгәннәргә беркадәр йомгак ясап, репортажда хикәяләүнең хәрәкәтчән, хисси һәм шәхси төсмерле булуын билгеләп үтәргә кирәк.

Хикәяләүнең хәрәкәтчәнлеге татар журналистикасында электән кулланылышта булган. Г.Тукайның “Уральскида хөррият бәйрәме” дигән

репортажы (Т. й., 1906, 2 сент.) әнә шул иншалау төрен кулланып төзелгән:

...Халык Недоносковны театрга кадәр кулдан-кулга күтәреп, хөрмәтләп китерделәр. Театрның эчендә чебен оча алмаслык дәрәҗәдә халык тулган иде. Һәрбер ишек төпләренә, бюрократларны кермәс өчен, халыкның үз арасыннан хосусый гаскәр дә сайлап куелды. Недоносков нотык сөйләргә тотыныр-тотынмас, әллә кайдан 30 лап атлы казак килеп чыгып, театр әйләнәсен чолгап алдылар. Бераздан 10-15 жандармалар эчендә шәһәрнең атаманнары вә пәлитсәмистерләре һәм шуларга охшашлары да килеп төшеп, борынгы горурлыклары вә күтәрелгән борыннары илә театр ишегеннән шарт-шарт басып кереп китмәкче булдылар; үзләре уйларынча, анда кереп, Недоносковны әллә нинди статья буенча арестовайт итмәкче иделәр. Ләкин теге халык гаскәре боларга юри кунакка караган күз белән карадылар, боларны ишектән кертү түгел, якын да җибәрмәделәр. Бичаралар, ары бәрелделәр, бире төртелделәр, - гөнаһ шомлыгы, халык гаскәре җибәрми.

Узган гасыр башы журналистикасы һәм әдәбиятының икенче бер күренекле вәкиле Сәгыйть Рәмиевның “Йорт басучылар” (Т. й., 1906, 23 июль) репортажында хикәяләүнең шәхси төсмере аеруча көчле:

Өйгә кердек. Керсәк - ни күзең белән күрәсең?! Әллә нинди шалтыравыклы-ялтыравыклы төймәләр таккан пристав вә полицейскилар, әллә нинди эленке-салынкылы баулар асылындырылган жандармнар утыралар. Йозакны ватып кергәнәр, бүлмәләребезне туздырып ташлаганнар. Безне көтеп утыралар.

Керүебезгә безне чишендереп, коралларыңыз юкмы дип, кесәләремезне тенти башладылар, һичбер зарарлы нәрсә таба алмадылар. Акчаларымызны алалармы инде дип курыккан идек, ярый акчаларны алмадылар. Моның соңында сумкаларны, чемоданнарны тентергә керештеләр. Сумка вә чемоданнарның хуҗалары өйдә юкка күрә, ачкычлары булмагач, аларны ваттылар. Зарарлы нәрсә тапмадылар, фәкать һәртөрле хатлар вә кирәкле кәгазьләремезне алдылар.

Бу өзектә вакыйганың көтелмәгәнлеге, тиз арада узуы *ни күзең белән күрәсең* конструкциясе, шулай ук *керсәк, керүебезгә* фигыльләренең форма һәм мәгънәсе аша тормышка ашырыла, автор катнашы исә фигыль һәм алмашлыкның беренче зат формалары һәм тартым кушымчалары аша белдерелә.

Югарыда китерелгән өзектә репортаж текстларында еш очрый торган икенче бер иншалау төрен — тасвирлауны да күрергә була.

Тасвирлау билгеле бер урындагы предметларны яки шул урында бер мизгел эчендә булган эш-хәрәкәтләрне санап чыгуга хезмәт итә. Тасвирлауны берничә төргә бүлеп карарга мөмкин. Әйтик, түбәндәге бүленеш бар: 1) хәзерге заманны сурәтләүче; 2) үткән заманны сурәтләүче; 3) атаучы тасвирлау.

Беренче төргә караган тасвирлауның ничек төзелүенә игътибар итик:

Ара-тирә яңгыр астында кымшанмыйча диярлек басып торган ОМОНчыларның калканнары дөмбердәп җиргә ава. Кыенсынып кына тагын күтәрәләр. Төрлесендә төрле йөзләр. Алларына килеп "Азатлык" дип кычкыручыларга кайберсе туры карый алмый... Мәйдан гөрли. Мәйдан эшли (Ш.К.).

Тасвирлауда, күргәнебезчә, вакыйга бара торган урынның төрле нокталарында бер үк вакытта булган эш-вакыйгалар бәян ителә.

Тасвирлауның тагын бер төре, атаучы дип атала торганы, аеруча репортаж текстының башлам өлеше өчен хас. Язманың башында табигатьне, әйләнә-тирә чолганышны, урын һәм вакытны сурәтләп бирү нәтиҗәсендә автор укучыны вакыйга эченә “кертеп җибәрә”:

Тышта ноябрь. Көн болытлы, яңгырлы. Аны озатырга килүчеләрнең йөзләре караңгы (Татарстан хәбәрләре, алга таба - Т.х.).

Атаучы тасвирлауда нинди дә булса бер әйбер, бер урын иң характерлы сыйфатлары аша сурәтләп бирелә. Нәтиҗәдә укучы өчен моңа

кадәр бөтенләй билгеле булмаган әйберләр аның күз алдына шактый тулы килеп баса.

Атаучы тасвирлауда мәгънәви бөтенлек параллель бәйләнеш нәтиҗәсендә дә тормышка ашырыла. Бу ысул белән атаучы тасвирлау барлыкка китерүнең төп чараларына түбәндәгеләр керә:

а) текстны атау җөмләләрдән төзү:

Төн. Караңгы. Бөтен дөньяда тынлык (В.Т.).

б) исем хәбәрләр куллану:

Көн чалт аяз, кояшлы. Бүгенге тантанага җыйналган кешеләр дә шат, көләч. Каршыбызда - бәйрәм поезды (В.Т.).

в) фигыльнең үткән заман <u>-ган/-гән</u> формасын куллану:

Биредә барысы да - класс бүлмәләре, актлар залы, мастерскойлар, ашханә - барысы да бүгенге көн таләпләренә җавап бирерлек киң, иркен, якты һәм заманча җиһазланган. Котельные газга тоташтырылган. Ишек аша гына нәни дуслары - балалар бакчасы урнашкан... Шунысы куанычлы: татар халкының күренекле мәгърифәтчесе Шиһабетдин Мәрҗанинең музей бүлмәсе дә урын алган биредә. Инде аны, әдибебезнең шәхси әйберләрен туплап, җиһазлап куярга да өлгергәннәр (В.Т.).

Репортажда автор сөйләменнән башка чит сөйләмне дә очратабыз. Бу жанрда чит сөйләмнең функцияләнүе шуның белән үзенчәлекле: ул анда кыска була, берничә җөмләдән генә тора. Чит сөйләм монда автор сөйләменең монотонлыгын киметү, аны җанландыру максатында кулланыла. Чит сөйләм аша вакыйга барышында журналист ишеткән мәгълүматлар, вакыйгага карата анда катнашучыларның бәясе, уй-кичерешләре белдерелә ала. Ул шулай ук авторның нинди дә булса фикерен раслау, дәлилләү максатына хезмәт итәргә дә мөмкин. Вакыйга барышында журналист тарафыннан ишетелгән һәм вакыйганың табигыйлеген көчәйтүгә хезмәт итә торган сүзләр дә чит сөйләм аша бирелә ала. Чит сөйләмгә мөрәҗәгать итүне татарча беренче репортажлардан ук табарга мөмкин. Г.Тукайның югарыда искә алынган

репортажына кабат мөрәҗәгать итеп, анда чит сөйләмнең ничек файдаланылуын карыйк:

Бюрократлар, аптырагач: “Әллә безне танымыйсызмы? Без - начальство бит! Без үзлегебездән килмәдек, закон куша бит”, - диделәр. Халык та: “Беләбез, беләбез, безгә кем икәнегезне сөйләмәгез! Без сезне бик яхшы таныйбыз”, - дип җаваплаңдылар.

Әхласыйль, алар бик озак тартышсалар да, бернәрсә дә чыкмагач, бичаралар, тәпи-тәпи генә, килгән юллары берлән киттеләр. Теге, театр әйләнәсен чолгап алган казакларның да яртысыннан күбрәге, үзләрен ни өчен чакырганнарын аңлагач та: “Без кеше үтермибез!” - дип кайтып киткәннәр иде. Недоносков та һәр хәрефе халыкның ихласын арттыра торган хотбәсен сөйләп бетерде. Халык аны тагын уч төпләренә күтәреп чыгардылар. “Урра! Урра! Да здравствует свобода! Бетсен халык каныннан алтын ясау!” тавышлары “Сәет Баттал” китабындагы әллә кем батырның нәгърәсе шикелле бөтен шәһәрне яңгыратты.

Кайбер репликаларны русча, ягъни үзе ишеткәнчә биреп, Тукай сөйләмне чынбарлыкка якынайткан.

Беренче апрель бәйрәменнән репортажында журналист Р.Гаффаров вакыйганың җанлылыгын белдерү максатында текстны диалог рәвешендә үк корган:

- Телевизор сатам, кем ала?

Арадан берсе шулай дип сөрән салды.

- Күпме сорыйсың, энекәш?

- Шалкан бәясе! Кесәң калынмы соң?

- Өч тәңкә.

- Мә ал, - ди егет, зур тартмадагы телевизорны күрсәтеп.

- Миңа гына сат, энекәш, биш тәңкә бирәм.

- Ә мин унны...

- Егерме биш! (С.Т.)

Шулай итеп, репортаж текстында барлык элементлар вакыйганы җанлы һәм хисле тасвирлауга хезмәт итә.

Мисаллардан күренә ки, репортаж язучы журналисттан игътибар, күзәтүчәнлек таләпителә. ул вакыйганың мөһим якларын күздән ычкындырмаска, шул ук вакытта кызыклы детальләрне дә күреп алырга бурычлы. Бу детальләрне ул үзенең репортажында укучының игътибарын җәлеп итә торган элемент, вакыйганы тулырак ачып бирүче өстәмә чара яки образ буларак та файдалана ала. Казан шәһәрендә **яңа** балалар кафесы ачылуга багышланган бер репортажда автор үзе игътибар иткән бер детальне – төрле әкият геройларының стенадагы рәсемнәрен – язманың үзәгендә торучы бер образга әйләндергән. Яңа бинада журналистны иң беренче әкият геройлары «каршылый», алар аны бу яңа бина, анда эшләүчеләр белән «таныштыралар», соңыннан бергәләп «озатып калалар».

Сурәтләнә торган хәлләргә мөмкин кадәр объектив бәя бирү, аларны газета укучы күзалларлык итеп тасвирлый белү өчен, вакыйгада үзеңкатнашу зарури булган кебек, тема буенча гаять белдекде булу да сорала. Ягъни, үзең тасвирлый торган объектның бөтен үзенчәлекләрен, нечкәлекләрен белгәндә генә, аның кирәкле һәм кызыклы якларына игътибар итә аласың, бәяң дә объектив була. Менә шуңа күрә журналистлар репортаж язуның нәтиҗәле бер алымы булган «һөнәр алыштыру»га мөрәҗәгать иткәлиләр.. «Һөнәр алыштыру» - теманы киңрәк ачып бирү максатында тормышның теге яки бу өлкәсендә хезмәт күнекмәләре алу, яңа һөнәр үзләштерү. Бу алымга М.Кольцов, А.Гудимов кебек атаклы репортерлар нигез салган. М.Кольцов, мәсәлән, такси хезмәтенең проблемаларын ачыклау өчен өч көн буе такси йөртүче булып эшли. Нәтиҗәдә, репортаж жанрының классик үрнәгенә әверелгән "Таксида өч көн" исемле язма туа. "Үлем өлмәге" дигән репортажны язу өчен исә, М.Кольцовка хәрби самолет белән күккә мөнергә туры килә. Бөек Ватан сугышы елларында күп кенә татар журналистлары да «һөнәрләрен

алыштырдылар", окоплардан торып, халкыбызның фронттагы батырлыклары турында сөйләүче үлемсез репортажлар иҗат иттеләр...[14]

Бүгенге матбугат органнарыбыздан аеруча “Комсомольская правда” газетасы журналистларының һөнәр алыштыру алымын даими уңышлы тормышка ашыруын билгеләп үтәргә мөмкин. Әлеге газетаның махсус хәбәрчесе Ярослава Танькова бер ай буе Төркиядә ватандашларыбыз ял итә торган урыннарда төрле һөнәрләр башкарды һәм соңыннан газетада гаять кызыклы репортажлар сериясе бастырып чыгарды.

Контроль сораулар:

1. Репортаж һәм хисап жанры арасындагы уртак һәм аермалы сыйфатлар нинди?
2. Репортажда авторның роле нидән гыйбарәт?
3. Нәрсә ул "һөнәр алыштыру" алымы?
4. Репортажга хас тел-стиль үзенчәлекләре турында сөйләгез.
5. ?зегезнең күзәтүләр нигезендә татарча иҗат итүче репортаж осталарын атагыз.

Биремнәр

1. Хрестоматиядәге әсәрләр мисалында "һөнәр алыштыру" алымының мөмкинлекләрен ачып бирегез.
2. Татар телендә иҗат итүче берәр журналистның репортажларына күзәтү ясагыз.
3. Үзегез катнашкан берәр вакыйгадан репортаж языгыз.

[14] Кара: Айнутдинов А.К. Летопись подвига. – Казань, 1984. – 110 с.

Интервью

Интервью (инглизчәдән тәрҗемә иткәндә "әңгәмә") - матбугатта бастыру яисә радио, телевидение аша тапшыру өчен журналист тарафыннан бер йә булмаса берничә кеше белен үткәрелгән әңгәмә. Монда инде факт/вакыйга авторныкыннан да битәр аның абруйлы әңгәмәдәшенең фикер-мөнәсәбәтләре аша яктыртыла.

Интервью, иҗтимагый әһәмияткә ия булган вакыйганы яктыртыл кына калмыйча, тормышыбыздагы мөһим мәсьәләләрне чишү, аерым бер шәхеснең эчке дөньясын ачып бирү һ.б. максатларда язылырга мөмкин. Шуна күрә интервью жанрында иҗат ителгән барлык газета әсәрләрен хәбәри төркемгә генә бикләп кую дөрес булмас иде. Әйтик, журналист республикабызның икътисади хәлен яхшыртуга бәйле мәсьәләләр турында берәр галим беләән тәфсилле әңгәмә кора икән, билгеле, мондый интервьюны аналитик жанрлар төркеменә кертергә кирәк.

Бу бүлектә без интервьюның хәбәри төрен, ягъни иҗтимагый әһәмияткә ия булган вакыйга яки факт уңаеннан аны газета укучыга оператив хәбәр итү, аңлатып бирү, аңа дөрес бәя бирү максатында язылганнарын тикшерербез.

Хәбәри жанрлар системасында интервью гаять зур роль уйный. Ул бу төркем өчен бик кирәкле сыйфатларга - объективлыкка, ышандыру көченә ия. Чөнки журналист иң ышанычлы һәм иң абруйлы чыганакка - яктыртыла торган хәлләргә турыдан-туры катнашы булган, аның турында иң хәбәрдар, иң компетентлы кеше сүзләренә таяна.

"Интервью" термины үзе ике төрле мәгънәгә ия. Беренчедән, ул жанр төшенчәсен аңлатса, икенчедән, төрле кешеләр белен әңгәмә корып, мәгълүматлар туплау дигән сүз. Башкача әйтсәк, газетаның барлык жанрларында иҗат иткәндә дә журналист үзе яктырта торган вакыйгага күпмедер күләмдә катнашы булган бер яисә берничә кеше беләән әңгәмә (ягъни, интервью) үткәрә. Хикмәт шунда, интервьюдан кала башка барлык жанрларда бу әңгәмә язма өчен мәгълүмат туплауның бер чарасы гына, булса, интервью

жанрында ул туры газета битенә күчә. Билгеле, газета битендә дөнья күргәнче, ул, жанр таләпләренә туры китереп, әдәби эшкәртелә.

Интервьюның нигезен әңгәмә, ягъни диалогик сөйләм тәшкил итә, дидек. Шул ук вакытта теоретик әдәбиятта бу жанрның интервью-монолог дигән төрен дә аерып чыгаралар. Интервью-монолог журналистның бер соравы һәм әңгәмәдәшнең шул сорауга бер җавабыннан тора. Жанрның бу төре кайсы очракларда кулланыла соң? Бер генә факт, эпизод турында кыскача хәбәр итәргә, аңа бәя бирергә кирәк булганда, журналистны (димәк, газета укучыны да) бер генә сорау кызыксындырганда, әңгәмә үткәрүнең шартлары уңайсыз булган очракта, вакыт тарлыгы комачаулаганда һ.б. Интервью-монологның башлам өлешендә, кагыйдә буларак, әнгәмәдәш белән таныштырыла һәм аңа сорау тәкъдим ителә. Текстның шуннан соңгы өлешен әлеге сорауга җавап тәшкил итә. Түбәндәге өзек интервью-монологның үзенчәлеген ачык күрсәтеп тора:

Бәхет юлдаш булсын, милләттәшләр!

Яңа ел алдыннан хәбәрчебез Токио шәһәрендә яшәүче, "Мухаджетрейдинг КО" сәүдә фирмасы директоры милләттәшебез Таминдар Мөхит әфәнде белән телефон аша элемтәгә керде һәм аңардан японнарның, шул исәптән анда яшәүче бер төркем татар гаиләләренең, Яңа елны ничек каршы алулары хакында сөйләвен үтенде.

- Без Азияда яшәсәк тә, Яңа елны, гадәттә, җир шарының башка мәмләкәтләрендәге кебек үк каршы алабыз. Декабрь урталары җитәрәк урамнарда, җәмәгатъ урыннарында, фатирларда бәйрәм ыгы-зыгылары башланып китә. Офислар, учреждениеләр ябыла. Һәркем ял итә. /.../ (Ш.К.)

Текстның калган өлеше да башта куелган сорауга җавап рәвешендә дәвам итә һәм артык озынга сузылмый. Бу очракга әңгәмә телефон аша гына барган, журналистка интервью бирүче белән иркенләп с?йләшер өчен тиешле шартлар булмаган.

Монолог рәвешендәге интервьюларда бу жанрның асыл сыйфатларыннан берсе булган әңгәмәлелек принцибы беркадәр бозылса да, аерым очракларда аны куллану бик урынлы була.

Интервью-диалогта исә нәкъ менә шул сыйфат - кара-каршы сөйләшү, әңгәмә кору рухы саклана да инде. Шуңа күрә интервью-диалог - вакытлы матбугатта шактый киң таралган жанр төре.

Интервью-диалог – берничә "сорау-җавап" бөтенен берләштерүче текст. Сорау, гадәттә, журналистныкы, җавап - интервью бирүченеке. Интервьюның әлеге төре вакыйга/фактны һәръяклап, бөтен нечкәлекләре белән яктыртырга, аңа белгеч күзлегеннән бәя бирергә мөмкинлек тудыра. Журналист әңгәмәдәшкә вакыйга белән бәйле һәртөрле сорауларны бирергә хаклы. Мәсәлән, Башкортстанда татар телендә яшьләр газетасы чыга башлагач, "Кызыл таң" газетасы хәбәрчесе шушы вакыйга уңаеннан яңа газетаның баш мөхәрриренә сораулар белән мөрәҗәгать итә һәм бу басманың барлыкка килү сәбәпләре, аның республика тормышында тотачак урыны, аудиториясе, юнәлеше, форматы, эшләнеше һ.б. хакында сөйләвен үтенә. Мөхәррирдән башка бу сорауларга, мөгаен, беркем да тулы итеп җавап бирә алмас иде.

Күп кенә интервьюлар тормышыбыздагы мөһим фактларга, вакыйгаларга, күренешләргә төпле аңлатма бирү максатында языла. Казан шәһәрендә шундый хәбәр таралган иде: имеш, Чабаксарда авария булган һәм йөзләгән тонна фенол тиздән Казанга килеп җитәчәк. Бу имеш-мимеш уңаеннан газеталарыбызда республиканың табигатьне саклау министрлыгы һәм Казан шәһәре җитәкчелеге белән интервьюлар басылып чыкты. Белдекле кешеләрнең фактка аңлатма бирүе халыкны тынычландырды.

Интервью формасындагы белгеч киңәшләре да газеталарда еш урын ала.

Интервью-диалогта журналист белән интервью бирүче арасында урнашкан мөнәсәбәтләр чагылыш тапмый калмый. Бер төрле интервьюда алар, үзара дустанә мөнәсәбәт урнаштырып, ачыктан-ачык һәм иркенләп сөйләшсәләр, икенчесендә (мәсәлән, тәнкыйди характердагы интервьюда) әңгәмәдәшләр арасында ераклык саклана һәм мондый очракга журналист

темадан читкә тайпыла алмый, әңгәмәне жанландыру алымнарына да бик еш мөрәҗәгать итми. Төрле дәрәҗәдәге кешеләр белән рәсми темага интервьюлар оештырганда да, импровизациягә бирелеп китә алмыйсың, гадәттә, алдан әзерләнгән сорауларны бирә белән генә чикләнәсең. Ә инде әңгәмәне жанландырырга, әйтик, шәхсирәк пландагы сораулар бирергә мөмкинлек туа икән, аны да кулдан ычкындырмаска кирәк.

Темасы мөмкинлек биргән очракта интервью алучы журналистның үз фикерләре белән уртаклашуы, үзенең позициясен ачык белдерүе язманың нәтиҗәлелеген күпкә арттыра. Интервью бирүче кеше генә түгел, журналист та кызыклы идеяләр, эшлекле тәкъдимнәр әйтергә мөмкин:

> *— Мөнир Әмирович, бая Сез телгә алган шомлы, ташландык ихаталар язмышына тагын бер тукталыйк әле. Авылның урта бер өлешендә рәттән өч йорт буш тора. Бер дигән уңдырышлы җирне чүп үләннәре басып киткән. Әгәр шунда җиләк-җимеш һәм яшелчә бакчасы ясасак, файдалы булмас микән? /А.у./*

Газета журналистының бу эшлекле тәкьдимен житәкче постта эшләүче әңгәмәдәш тә хуплап ала һәм аны киләчәктә тормышка ашырырга вәгъдә бирә.

Текст эчендә диалогларның үзара ялгануына бәйле рәвештә интервьюның йомшак күчешле һәм кискен күчешле төзелеш төрләрен аерып чыгарырга мөмкин. Йомшак күчешле текстларда диалоглар үзара тыгыз бәйләнгән, журналистның беренче соравыннан тыш калганнары әңгәмәдәшнең алдагы җавабын укыганнан соң гына аңлашыла. Бу төр үзенчәлеккә ия булган текстның сорауларына игътибар итик:

1) Лима ханым, узган ел, һәммәбезгә мәгълүм булганча, японнар календаре буенча Әтәч елы булды. "Әтәч"кә мөнәсәбәтегез?

2) Нәкъ өстенә бастыгыз. Үзем дә сүзне шуңа бормакчы идем. Узган елгы шул вакыйгаларны кабат күңелдә яңартыйк әле.

3) Шул шаукымның тагын берничәсен атасагыз иде.

4) Инде туган илгә, Идел-йортыбыз вакыйгаларына әйләнеп кайтыйк (Т.х.).

Кискен күчешле текстларда исә диалоглар бик тыгыз бәйләнештә түгел, аларны аерым-аерым да аңлап була. Чөнки сораулар алдагы диалогның дәвамы түгел, ә яңа темага алып кереп китүче күперчекләр ролен үтиләр:

1) Илдус Габдрахманович, иң элек якынлашып килүче юбилеегыз белән котларга рөхсәт итегез. 70 ел — аз гомер түгел. Төрле еллар төрле шаукымнар тудыра. Бераз үткәннәргә күз төшереп китик әле.

2) Бүгенге көндә күпме укучыгыз бар? Алардан нинди һөнәр ияләре әзерлисез? Гомумән, бүгенге хәлегезне тасвирлап үтсәгез иде.

3) Булачак укытучыларга белем бирүчеләр үзләре дә чын мәгънәсендә гыйлем ияләре булырга тиеш. Кемнәр алар?

4) "Сәламәт тәндә — сәламәт рух" дигән әйтем бар. Спорт өлкәсендә хәлләрегез ничек? (М.)

Йомшак күчешкә ия булган текст, гадәттә, әңгәмәнең иркен шартларда үтүе, журналистның алдан әзерләнгән сораулар белән генә чикләнмичә, сорауларны җавапларның эчтәлегенә карап бирүе турында сөйли. Кискен күчешле текст — рәсмилек билгесе. Әңгәмәнең табигыйлегенә хилафлык килсә дә, рәсми язмаларның кискен күчешкә ия булуы — кимчелек буларак каралырга тиеш түгел. Сораулар да, җаваплар да ныклап уйланган булырга тиеш бит. Рәсми әңгәмәдәшкә сораулар хәтта алдан, интервью башланганчы ук бирелгән булырга мөмкин.

Йомшак күчешле текст әңгәмәнең табигый агышын ассызыклый, катнашу төсмерен көчәйтә. Мирхәт Хөснимәрдәновның "Иртәгесе көнгә каршы төндә" дигән интервьюсы (С. Т., 1992, 1 гыйнв.) — әлеге төр текстның бер мисалы. Әсәр авторның монологик кереше белән башланып китә:

Татарстан Югары Советы бинасы түбәсендә өч төстәге үз флагыбыз җилферди башлады. Анда аны кайчан, кем менгезеп куйганын да беләбез. Ә кем теккәнен сораштырырга башка килмәгән. Яңа ел алдыннан ике көн буе эзләдем мин ул фабриканы.

Тырышкан табар, диләр. Парламент депутатлары да озак тырыша торгач, үз флагыбызны булдырдылар. Аның беренчесен "Татшвейбыт" берләшмәсенең 3 нче цехында теккәннәр. Шул уңайдан берләшмә генераль директоры урынбасары Л.Ионова интервью бирде.

Текстның калган өлеше диалогик төзелешкә ия:

- Безгә тарихи бурыч төште. ?өмһүриятебезнең үз флагын беренче булып тектек.

- Шул берне генәме?

- Юк, зурысын уннан артык тектек инде.

- Кечкенәләре дә бармыни?

- Бар шул. Сувенир флагчыклар. Чит илдән килгән делегатларга бирергә дип тектерделәр.

- "Бар шул" дип ник авыр суладыгыз, Ләйлә Шәймиевна?

- Шуның өчен шелтә алганга ул. Зурларын 4 фасон тектек. Әзерлибез - кабул итмиләр. Кечкенәләре калып торган иде. Шуңа әрләделәр.

- Беренчесен кемнәр текте?

- Светлана Шмакова белән Марина Кашапова.

- Урыс кызларымыни?

- Ник, әллә гаепме?

- Гаепләп әйтмим.

- Башкаларын тегүчеләр арасында татар кызлары да бар. Тик менә кирәкле тукыма табып булмый. Кытлык чак бит.

- Ә заказлар күпме?

- Күп. Барлык районнарга, учреждениеләргә дә кирәк.

- Без: "Кызыл флаг, ямьле флаг, яшәтербез мәңгегә", - дип җырлый идек.

- ?ыр башка да, чор башка шул.

- Яңа ел белән Сезне, Ләйлә Шәймиевна!

- Рәхмәт. Сезне дә котлыйм.

Газета-журналларда диалогик текстларның күпчелеге өлешчә йомшак, өлешчә кискен күчешле төзелешкә ия. Журналистның осталыгы аларны дөрес һәм урынлы урнаштыра белүдән гыйбарәт.

Диалогик текстларга карата куела торган мөһим таләпләрнең берсе — әңгәмәдәшнең сөйләм үзенчәлекләрен мөмкин кадәр саклау. Моның өчен автордан телнең мөмкинлекләрен яхшы белү сорала. Кызганычка каршы, күпчелек язмаларда әйтелгән таләп төгәл үтәлми.

Бу уңайдан Фатих Әмирханның "Әльислах" газетасында чыкан һәм интервью формасында язылган "Зурлар белән мәдрәсәләр берләштерү хакында мөзәкәрә" дигән әсәре игътибарга лаек.

Текстны автор тема һәм әңгәмәдәшләр белән таныштырудан башлап җибәрә:

"*Әльислах" мөхбирлеге сыйфатым белән Казан мәшһиренең мәдрәсәләр берләштерү хакындагы фикерләрен сораштырып йөрдем. Әүвәл бу мәсьәләдә бик мөһим урын ишгаль иткән кешеләр дип муллаларга барырга карар биреп, алар арасында да картрак вә зуррак дәрәҗәлесе дип ахундка бардым.*

Аннары автор Йосыф ахун белән булган сөйләшүен тәкъдим итә:

Йосыф хәзрәттә.

Мин:

- Тәхсир, хәзер мәдрәсәләр берләштерү мәсьәләсен кузгаттылар. Шул тугрыда сезнең дә фикерегезне белергә телим.

Ахун:

- Әнәтерәк, инде һәммәсен дә бер ясыймыз диләрмени? Әнәтерәк, мулла Галимҗанмы инде? Шулай димени инде?

Мин:

- Тәхсир, шулай диләр.

Ахун:

- Әнәтерәк, байлар ни диләр соң?

- Белмим.

- Әнәтерәк, без байлардан узмамыз инде. Шулай инде. Мулла Галимҗан минем мәдрәсәне бетермәкче димени инде?

- Хуш, хәзрәт!

(Чыгып киттем. Галимҗан хәзрәткә бардым.)

Ф.Әмирхан әңгәмәдәшенең сөйләм үзенчәлекләре аша аның характер чалымнарын да күрсәтеп бирә алган. Сорауга сорау белән җавап бирү — икеләнү, ныклы фикер булмау билгесе. Автор ахунның сөйләм үзенчәлекләре (*әнәтерәк, инде* кебек паразит сүзләр куллану) аша аның үз фикерләрен беркадәр ашык-пошык, уйлап җиткермичерәк әйткәнен дә белдергән.

Ә менә Галимҗан хәзрәтнең уйланган, төпле һәм төгәл җаваплары аның тыныч холыклы, вәкарьле (автор моңа үзе дә басым ясый) кеше икәнлеген ассызыклый:

Галимҗан хәзрәттә.

- Тәхсир, тәүхиде мәдарис хакында фикерегез?

(Вәкарь белән генә):

- Мәдрәсәләрне берләштерү, инша аллаһ, файдадыйн хали булмаз. Аллаһ вә рәсүлә ризалыгы сарый ашыгучылар бу эштә гыйнад вә мөкябәрә итмәскә ляземдер. Берләштерү матди җәһәт сартин да файдадин хали булачак дәгел.

- Рәхмәт, әссәләмәгаләйкем.

Кыска гына диалогтан әңгәмәдәшнең гаять динле кеше булуы (*инша аллаһ, аллаһ вә рәсүлә ризалыгы сарый ашыгучылар* кебек гыйбарәләр), өстәвенә махсус дини гыйлемнәргә ия кеше (сөйләмдә гарәп сүзләренең күп кулланылуы) икәнлеге ачыклана.

Тагын берничә дин әһеле янында булганнан соң, Ф.Әмирхан газета мөхәррирләренә сорау бирә:

Әүвәл, гыйлем-тәрбиягә интисаблы вә күптән мәдрәсә ислахы фикерен сөйләп йөргән кеше дип, Һади Максудига бардым.

Мин:

- Һади әфәнде, мәдрәсәләрне берләштерү тугрысында фикерегез?

Ул:

- Без инде күптәнге исламият либералларыннан бит. Без бу тугрыда бик күп хезмәт иттек. Бик муафикъ эш, бик муафикъ эш! Мин бу фикерне "Мизанел-әфкяр"да да язарга уйлаган идем. Ләкин ул вакытта иртәрәк иде әле, иртәрәк әле. Безнең энемез Садри әфәнде дә ул фикергә күп хезмәт иткән кеше. Әле Сорбонда укып кайткан энемезне әйтәм.

Мин:

- Тиз вөҗүдкә чыгар дип уйлыйсызмы?

Ул:

- Әле үзем дә әйтмәкче идем. Яшьләр ашыгалар. Аз дигәндә биш ел узарга кирәк. Менә без тәҗрибә белән йөримез. Бу эшнең башында без идек инде.

Алдагы әңгәмәдәшләр белән чагыштырганда Х.Максудиның сөйләме гади һәм аңлаешлы. Шәхси сөйләм үзенчәлеге — аеруча мөһим дип санаган фикерләрен кабатлап, абсым ясап әйтүе (*Бик муафикъ эш, бик муафикъ эш! Ләкин ул вакытта иртәрәк иде әле, иртәрәк әле.*).

Чираттагы әңгәмәдәш булган Борһан Шәрәфнең сөйләм үзенчәлекләре аеруча ачык күренү:

Мин:

- Мәдрәсәләрне берләштерү хакында фикерегез?

Ул:

- Фикерме? Һа, һа, фикер! Дөньяда нинди фикер дигән нәрсә ул? Шул Казан муллаларыннан, шул бары алар өстеннән кеше көлсен өчен генә яратылган кешеләрдән нинди булса да эш көтү! Әйтсәңез лә, зинһар, кайда алар нәрсә булса да берәр эш эшли алганнары бар? Кайда алар катышып, шул нәрсәгә зарар китерми калганнары бар? Муллалар эш башында булганда, берләштерү дә булмый, башка да булмый!

Мин:

- Алай булгач, сезнеңчә, муллалар исән булганда, мәдрәсәләр берләштерү кирәкми икән?

Ул (бик ямьсез генә кулларын бутап кычкырып):

- Муллалар бетмичә, мәдрәсәләр белән бер эш эшләр хәл юк!

- Хушыңыз!

(Чыктым.)

Соңгы әңгәмәдәшнең сөйләм үзенчәлекләреннән аның кызу канлы, тиз кабынучан һәм хисле кеше булуын чамаларга мөмкин. Аның бу үзенчәлекләрен сорау, өндәү һәм тойгылы җөмләләр, риторик сораулар, ымлыклар (*һа-һа*), кабатлаулар (*фикерме - фикер; шул Казан муллаларыннан - шул бары алар өстеннән кеше көлсен өчен генә яратылган кешеләрдән; кайда эш эшли алганнары бар - кайда зарар китерми калганнары бар; берләштерү дә булмый - башка да булмый*), шулай ук ремаркалар аша әңгәмәдәшнең ишарәләрен тасвирлап бирү кебек чаралар тапшыра.

Әсәр автор нәтиҗәсе рәвешендәге түбәндәге очлам белән төгәлләнә:

Мәзкүрә әфкяре кыл кадәр улсын ихтирафтан башка тәблигъ иттек.

Югарыда карап үткән әсәр - татар вакытлы матбугаты барлыкка килгән чорда дөнья күргән сирәк интервьюларның берсе. Бүгенге мәгънәсендәге интервью жанр буларак шактый соңрак формалашкан. Шулай да интервьюга охшаш диалогик текстларның ярала башлануын инде XX гасыр башы матбугатында ук күрергә була. Г Тукай да үзенең кайбер журналистик әсәрләрендә бу формага мөрәҗәгать итә. Мәсәлән, “Мөкяләмә, яхуд мөсарәгате фикрәйн” (Фикер, 1906, 23 апр.) язмасында интервью жанры шәкертләргә бары тик дини белем бирү кирәклеге турындагы фикерне кире кагуга хезмәт итә. Әңгәмәдәш — конкрет кеше түгел, абстракт шәхес.

Гасыр башы журналистикасында конкрет әңгәмәдәше булмаган андый интервьюларны шактый очратырга була. Мондый төзелеш бигрәк тә сатирик миниатюраларда очрый. Менә “Азат” газетасыннан бер мисал:

Газета сатучы: Бу көн гәзит бик шәп.

Авыл кешесе: Ни бар, ни язган?

Гәзитче: Сезгә җир чыга.

Авыл кешесе: Чынлапмы, кайчан чыга?

Гәзитче: Апрель аенда, кар эрегәч (А., 1906, 20 февр.).

Интервью жанрының бер яралгысы буларак Галиәсгар Камалның “Йолдыз” газетасында басылып чыккан “Думаны истикъбаль” (Думаны каршылап) (1907, 12 сент.) дигән әсәрендә, гәрчә ул тасвирнамә булса да, интервью элементлары шактый.

Текстның баш исеме һәм башлам өлеше теманы белдерә, аның вакыт һәм урынын ачыклауга хезмәт итә:

Бу көннәрдә миңа Зөя өязендәге бер мөселман карьясында булырга тугры килде. 7 нче сентябрь җомга көн иде. Шинбә көн - 8 нче сентябрьдә волостьлардан вәкилләр сайлау көне идисә дә, мәсҗедтә бу тугрыда һичбер сүз ишетелмәде...

Әсәрнең төп фикере - авыл халкының сайлаулар хакында берни белмәве. Бу тезис авылдагы абруйлы кешеләрнең берсе белән әңгәмә аша дәлилләнә. Үзенең беренче соравын автор туры сөйләм аша бирә:

Бәлки, бунлар үзара бер карар биреп, бу хакта авыл халкы алдан киңәшеп куйганнардыр өмиде илә карьяның мөгътәбәр кешеләреннән берсеннән:

- Ни хәл? Бу ел Думага әгъза сайлау өчен волостьтан кемне вәкил итеп җибәрмәкче буласыз? - дип сорадым.

Ләкин җавап сорауга сорау рәвешендә яңгырый һәм төп фикерне исбатлый:

Бу сөалемә каршы ул кеше:

- Ник әле, ул Думага яңадан кешеләр сайлаячаклармыни? - диде.

Интервью тексты алга таба сорау өлешләрендә кыек сөйләм, ә җавап өлешләрендә туры сөйләм рәвешендә төзелә:

Мин буннан соңра Русиянең Думасыз тормаячагыны, һәрбер Дума таралганнан соңра, икенче Дума җыелачагыны вә буның өчен бу ел волостьлардан вәкилләр сайлау һәрбер өязләрдә иртәге көнгә тәгаен ителдекене сөйләгәч, бу кеше бик гаҗәпкә калып:

- Безгә һичбер әйткән кеше юк. Әле бу көннәрдә старотамыз да авырый. Аның урынына калган кешегә писер иртәгә дисәтникләрне җыеп, волостька килергә кушкан, волостьта сход була, дигән. Үзе ни өчен икәнен әйтеп җибәрмәгән. Алайса, ул шуның өчендер инде, - диде.

Текстның иң мөһим, йомгаклаучы өлеше буларак автор әңгәмәдәшенең түбәндәге сүзләрен китерә:

Соңра, сүзнең ахырындарак, бу кеше, янә үзләренең Думага бик хәтерләре калганлыкларыны белдереп:

- Без староста сайлап куямыз, ул да бер куйгач өч ел хезмәт итә. Думага ике мәртәбә ни кадәр мәшәкатьләнеп сайладык. Икесен дә җибәрделәр. Кемне сайласаң да, һаман шул булыр инде. Адәм һичбер вакыт фәрештә булмас, - диде.

Очламда язманың башындагы фикер тагын бер кат көчәйтелә:

Аңлашыла ки, халыкта сайлау эшләренә әһәмият бик уртадыр.

Әлеге текст, алда әйтелгәнчә, чиста диалогик төзелешкә ия түгел, нигезендә автор фикерләренә һәм әңгәмәдәш сүзләренә таянып дәлилләү ятканга күрә, аның жанрын интервью Һәм тасвирнамә кушылмасы буларак билгеләргә кирәктер. Г.Колахмәтовның “Азат” газетасында басылган “Государственный думага пассивный бойкот ясау” дигән язмасы (1906, 31 март) шундый ук үзенчәлеккә ия.

Шулай итеп Г.Тукай һәм Ф.Әмирхан, Г.Камал һәм Г.Колахмәтов язмалары, башка кайбер журналистларның әсәрләре аша инде XX йөзнең беренче унъеллыгында ук интервью жанры бөреләнә башлый.

Чын мәгънәсендәге интервьюларның берсе, аның интервью-анкета дигән төренә караганы, 1913 елда “Аң” журналының 22 нче санында басылып чыккан.

Бу текстта берничә әңгәмәдәшкә бер генә сорау куела: *Яңа елда ни телисез?* Бу сорау баш исеменә дә чыгарыла. Текстның башламы бу сорауны беркадәр тәгаенләштерә генә:

Бераз аңлашмак, җәмгыятебезнең алдында баручыларымыздан кайберләре илә халкымызны таныштырмак нияте белән "Аң" идарәсе Казанда булган гали каләм әһелләренә "Яңа елда ни телисез?" сөале белән мөрәҗәгать итеп, шуңа җавап язуларын үтенгән иде. Әфәнделәр латифә үтенечемезне кабул иттеләр. Без дә җавапларны әлифба тәртибе белән, гамәл вә өслүбләрен үзгәртмичә, түбәндә дәреҗ иттек.

Алга таба сораштырылган кешеләрнең җаваплары тәкъдим ителә:

Казан ханымнарының гомуми эшләргә катнашуларыны, үзләренә махсус җәмгыять ачуларыны телим.

Зәйнәп Хәсәнова.

Татар милләтенең якын бер заманда эшләнгән әдәби теле, бай әдәбиятлы, европалылар кеби чын мәдәни вә бай бер милләт булуын телим.

Г.Баттал.

Милли театрымызның мәдәни бер шәкелгә керүен, халкымызның театрга җитди күз белән карый башлавын, театр сәнгате гражданлык алып, уйнаучыларның да, театрга язучыларның да күбәюен һәм камилләнүен телим.

Галиәсгар Камал.

Текстта тагын шундый берничә җавап бар.

Күргәнебезчә, текстның төзелеше гаять гади. Анда бердәнбер сорау өлеше һәм аңа турыдан-туры б?йле берничә җавап өлеше бар (хәзерге интервью-анкеталарның төзелеше дә нәкъ әнә шундый).

Интервьюның үсеш юллары

Әгәр 1917 елның октябрь инкыйлабына кадәр артык катлаулы төзелешкә ия булмаган мондый интервьюлар шактый гына чыгып килсә,

совет чорында, җитмешенче елларга кадәр интервью жанрына сирәк мөрәҗәгать ителә. Үзәк газеталардан партия һәм дәүләт җитәкчеләре белән кайбер интервьюларның тәрҗемәләре генә күренгәләп ала. Мәсәлән, “Социалистик Татарстан” газетасында 1961 елда интервью жанрындагы бер генә текст дөнья күргән. Ул — Н.С.Хрущевның космостан очып кайткан Юрий Гагарин белән телефон аша сөйләшүе язмасы.

Хәтта 70-80 елларда, интервью жанры газета-журналларда үзенең ныклы урынын яулый башлагач та, аның мөмкинлекләре һәрчак тиешенчә файдаланыла алмады. Табигый сөйләм үзенчәлекләрен бирә алмау, монотонлык, рәсмилек өстенлек итте. Моның күрсәткечләре — шактый. Тел чараларын алсак, фигыльнең кайтым юнәлешенә еш мөрәҗәгать итү, алмашлыкларны ешрак күплек санда куллану. Төзелеш ягыннан исә текстларны кискен күчешле итеп оештыру. Бу — авторитар режим шартларында кешеләрнең үз фикерләрен, шәхси бәяләрен тиешенчә белдерә алмау нәтиҗәсе дә иде.

Узган гасырның 80-еллары азагыннан башлап, интервью жанры матбугатта гаять җанланып китте. Журналистлар аның мөмкинлекләрен тулы куәткә файдалана, төрледән-төрле яңа формаларын уйлап таба башладылар. Интервьюның йомшак күчешле төзелешкә ия булганнары аеруча еш урын ала, чөнки фикер төрлелеге шартларында җанлы, бәхәсле әңгәмәне чагылдыру ихтыяҗы артты.

Шул ук вакытта кискен күчешле төзелеш тә төшеп калмады. Ул хәзер күбрәк “читтән торып” интервью үткәргән очракта кулланыла. Әйтик, дәүләт эшлеклеләре, танылган сәясәтчеләр, сәхнә йолдызлары белән интервьюны кайбер газеталар үз укучыларының сорауларына нигезләнеп алалар. Мондый очракта журналистның роле иң кызыклы сорауларны сайлап алып, әзер диалогик бөтеннәрне мантыйкый эзлекле итеп тоташтырудан гына гыйбарәт була.

Интервьюның үзенчәлекле бер формасы буларак “үз-үзем белән интервью”ны да карарга мөмкин. Татар журналистикасында ул беренчеләрдән булып язучы һәм журналист Рабит Батулла тарафыннан кулланылды. Аның “Мәдәни җомга”да басылган “Телдә, фикердә, эштә берлек” дигән язмасы гадәти интервьюдан да бигрәк кешенең үз-үзе белән сөйләшүе рәвешендә язылган. Табигый, диалогларның сорау өлешләре дә, җаваплары да бер үк өслүбтә:

- Батулла ага, синең “Роберт” исеменнән ваз кичүеңне беләбез, ул турыда яздың да. Үзеңә “Роберт” дип түгел, “Батулла” дип мөрәҗәгать иткәнне хуплыйсың, әле менә ишеттем, имеш, хак булса, бу күп бәхәсләр, хуплау, хупламау уятачак. Чыннан да, түбәтәй-кәләпүш киеп кенә, түргә чатый-ботый эшләнгән шамаил элеп кенә татар-мөселман булып булмый. Чын татар-мөселман булу өчен аның йолаларын да, фарызларын да үтәргә кирәк. Ата кушкан исемне алыштырып кына...

- Дөрес, әмма түбәтәй-кәләпүшне салып атып кына урыс булып та булмый. Шамаилне салып таптап кына югары культурага ирешергә маташучылар да булды. Наданлыктан кылынган хаталарны төзәтергә тырышкан адәмне камчыларга ярамый.- Соң түгелме дим?

- Соң түгел. Гөнаһларны, хаталарны, ялгышларны юарга беркайчан да соң булмый...

Бу интервьюның үзенчәлекләреннән берсе — диалогларның сорау өлешләре еш кына җавап өлешенә караганда күләмлерәк. Кайбер сораулар әйтеп бетерелми, сорау һәм җавап өлешләренең бер-берсенә каршы килгән кебек тәэсир тудырылуы җавапларның катгыйлыгын көчәйтү өчен генә. “Әңгәмәдәш”кә “син” дип дустанә рухта мөрәҗәгать итү сөйләмнең табигыйлеген, шәхсилеген көчәйтә.

Ә менә диалогик төзелешле икенче бер жанр төре булган интервью-анкетада, киресенчә, шәхси төсмерләр аз чагыла. Аның асыл сыйфаты журналистның бер яки берничә соравына берничә әңгәмәдәш җавап бирүеннән гыйбарәт. Шуңа да биредә без югарыда карагандагы

кебек диалогиклар юк, “Аң” журналыннан китерелгән мисалдагы кебек бер үк сорауга берничә җавап бирелү.

Соңгы елларда төзелеше буенча интервью-анкетага охшаш тагын бер төр текст — “интервью-түгәрәк өстәл” шактый киң кулланыла. Шундый төр текстка бер мисал китерик. “Мәгърифәт” газетасындагы түгәрәк өстәл артында сөйләшүгә нигезләнеп язылган интервьюның төп соравы язманың баш исеменә үк чыгарыла: “Киләчәгебез латин беләнме?”. Шунысы да игътибарга лаек, әлеге баш исеме латин графикасында бирелгән.

Төзелешләре буенча охшашсалар да, интервью-анкета белән интервью-түгәрәк өстәл арасында ныклы аерма да бар. Беренче жанр төре хәбәр итү функциясен башкара, ә икенчесе мөһим проблема турында фикер алышуга багышлана һәм билгеле бер фикер яки фикерләр җыелмасын исбатлау яки кире кагу максатына хезмәт итә. Ул күләмлерәк тә була әле. Интервью-түгәрәк өстәлдә текст, анкета рәвешендәге интервьюлардан аермалы буларак, йомшак күчеш принцибы буенча да корыла ала, ягъни төрле әңгәмәдәшләрнең җаваплары бер-берсенә тоташып барырга мөмкин. Телгә алынган интервью-түгәрәк өстәлдән шуның бер мисалын китерик:

М.Зәкиев: ...Кабул ителгән очракта, алфавит тулысынча кереп беткәч, тагын бер махсус Указ булырга тиеш, монысы - алфавитның соңгы, камилләштерелгән вариантын кабул итү өчен.

Ә.Кәримуллин: Камилләштерү мәсьәләсен ун елга чигерергә ярамас, мөмкинлек бар ич әле - моны хәзердән үк эшләргә кирәк. Аннары. Хәрефләрнең вариантларын Дәүләт Советы комиссияләре тикшерәчәк, дидегез. Минемчә, бу эшне депутатларга тапшырырга ярамый.

Ф.Сафиуллин: Безгә, депутатларга, галимнәр бәхәсләшерлек бернинди урын калдырырга тиеш түгел. Дәүләт Советы бер генә мәсьәләне карарга тиеш: яңа алфавитны кабул итәргәме - юкмы...

Интервью-түгәрәк өстәл "Ватаным Татарстан" газетасы журналистлары тарафыннан киң файдаланыла. Әдәбият-сәнгать, тел, мәгариф, милләтара мөнәсәбәтләр, икътисад, авыл хуҗалыгы мәсьәләләренә багышланган әңгәмәләрдә шушы өлкәләрдәге иң абруйлы белгечләр, күренекле шәхесләр катнаша. Редакциянең "түгәрәк өстәл"е артындагы интервьюларына махсус сәхифәләр багышлана.

Җәмгыятебезнең демократияләшүе чорында, төрле фикерләрнең янәшә яшәеше өчен шартлар туган хәзерге заманда "түгәрәк өстәл" янында уздырылган интервьюларның әһәмияте күпкә артты. Төрле партияләр, политик хәрәкәтләр һәм агымнарның вәкилләре, менә шундый интервьюларда катнашып, бер-берсенең позицияләрен ачыклыйлар, җәмгыять өчен файдалы булган уртак фикерләргә киләләр.

Без карый торган жанрның интервью-зарисовка, интервью-сораштыру, пресс-конференция кебек төрләрен дә аерып чыгаралар. Болары инде - интервью алымы белән иҗат ителгән арадаш төрләр. Аларның исемлеген тагын да дәвам итәргә мөмкин булыр иде. Чөнки, интервью үзе күп кенә жанрларга үтеп керә алган кебек (алдарак без аның репортажда файдаланылуын күргән идек), аңа да газетаның башка жанрлары һәм журналистиканың башка эш алымнары шактый нык тәэсир итә.

Кызыклы интервью оештыру жиңел эш түгел. Бу жанр журналисттан ныклы әзерлек, башкалар белән тиз аралашу, уртак тел таба алу, кеше күңелен сизгер тою кебек мөһим сыйфатлар таләп итә. Интервью алдыннан аның максатын билгеләргә, теманы конкретлаштырырга кирәк. Нәрсә хакында, ничек сөйләшәсеңне алдан ук планлаштырганда, сорауларыңны әзерләп куйганда әңгәмәнең уңышлы чыгачагына өмет итәргә була. Тик сораулар максатка ярашлы булсын һәм әңгәмә нәтиҗәле үтсен өчен, күтәрелә торган мәсьәлә буенча әзерлекле булырга кирәк. Сүз бара торган тема турында белеп фикер йөртүче журналистка карата интервью бирүчедә дә хөрмәт тойгысы, ихтирам уяна. Бу очракта уртак тел табу күпкә җиңел.

Сөйләшүдә катнашачак кеше яки кешеләр турында алдан белешеп кую да максатка ярашлы. Кем ул? Сүзгә юмарт кешеме, әллә "әйе-юк"тан ары китә алмыймы? Күбрәк ниләр белән кызыксына? Дуслары бармы? Гаиләдә ничек? Мондый сорауларга җавап таба алган журналистка әңгәмә барышында киртәләр азрак очрый. Әлбәттә, бу сорауларга җавап эзләр алдыннан әңгәмәдәшне дөрес сайлау турында кайгыртырга кирәк: яктыртыла торган вакыйга турында хәбәрдар да, бу өлкәдә абруйлы да булсын ул.

Әңгәмә вакытында үз-үзеңне дөрес тоту зур әһәмияткә ия. Әңгәмәдәшне игътибар белән, чын күңелдән кызыксынып тыңлау, аны кирәкмәгән урында бүлдермәү, шул ук вакытта сөйләшүгә кирәкле юнәлешне биреп бару - болар барысы да интервью оештыручы өчен кирәкле сыйфатлар. Тәнкыйди интервьюда аеруча итагатьле булырга, сорауларны уйлап бирергә, кирәк очракта әңгәмәдәш белән эшлекле бәхәскә керергә дә әзер булырга кирәк. Билгеле, моның өчен алдан тупланган фактлар һәм дәлилләрнең булуы хәерле.

Интервью алганда диктофон, магнитофон кебек техник чаралардан актив файдаланалар. Бу, беренчедән, газетада басылып чыгачак язманың документальлегенә һәм төгәллегенә ирешергә мөмкинлек бирсә, икенчедән, игътибарны тулысынча әңгәмәнең үзенә туплау мөмкинлеген тудыра. Рәсми интервьюларда техник чараларның роле аеруча зур.

Интервьюның рубрикасы баш исеме шулай ук, мөһим композицион элементлар буларак, журналистның игътибар үзәгендә булырга тиеш. Газеталарыбыздагы "Очрашулар", "Безнең кунакхан?", "Казан кунагы", "Актуаль интервью", "Белгеч киңэш бирә", "Әллүки"нең "түгәрәк-өстәл"е", "Ачыктан-ачык сөйләшү" һ. б. рубрикалар укучының игътибарын җәлеп итәрлек. Баш исеменең дә кызыклысын, күзгә ташлана торганын сайлауда журналист иҗади эш итә ала. Еш кына әнгәмәдәшнең иң кирәкле, кызыклы фикерен баш исеме рәвешендә урнаштыру көтелгән нәтиҗәне бирә.

Интервью телне куллану ягыннан гаять үзенчәлекле жанр. Монда текстның тел һәм стиле журналистның сорауларына бәйле. Алар әңгәмәгә тиешле тон бирерге, гади һәм анлаешлы булырга тиеш.

Интервью алучы теләсә кайсы журналист, табигый, үз соравына мөмкин кадәр киңрәк һәм тулырак җавап алырга омтыла. “Әйе-юк”тан ары китә алмаучы әңгәмәдәш аны канәгатьләндерми. Журналист өчен дә, укучы өчен дә хәбәр ителә торган яңалык хакында әңгәмәдәшнең фикерләре, аның аңлатмалары мөһим була, интервьюда абруйлы, укучы өчен кызыклы шәхеснең уй-фикерләрен, нәтиҗә һәм бәяләрен бирү — төп максат.

Әңгәмәнең табигыйлеген саклау өчен, әлбәттә, мөмкин кадәр аның әйтмә сөйләм үзенчәлекләрен текстка күчерү дә кирәк. Бу таләп үтәлгән очракта катлаулы диалогик бөтеннәр дә җанлы сөйләм төсмеренә ия була

Диалогик текстларның теле һәм стиле әңгәмәнең тематикасына, әңгәмәдәшнең үзенчәлекләренә бәйле. Шул ук вакытта журналистның сораулары да зур әһәмияткә ия. Алар әңгәмәгә тиешле тон һәм юнәлеш бирә. Билгеле, диалогларны? сорау өлеше сорау җөмләләрдән генә тормаска да мөмкин. Бу очракта аеруча түбәндәге вариантлар аеруча еш кулланыла:

а) үтенеч:

- Быелның ун аендагы эшләрегез хакында берничә сүз әйтсәгез икән, Марат Галимҗанович (Т.х.).

б) фараз кылу:

- Син элек совхозда бизәүче-рәссам булып эшли идең. Яңа урында бу һөнәреңнең кирәге чыккалыйдыр... (С.Т.)

в) берәр төрле ситуацияне күз алдына китерү:

- Зөлфәтне бүген илһам нигәдер читләтеп уза - башланып та тәмамланмаган шигыре киреләнә, яңа көй урынына аңын шәһәр ыгы-зыгысы, машина шавы, ишекнең арткы ягында кемнәрнеңдер әйткәләшүе күмеп китә. Ул бу очракта нишли, үз күңелен ничек юата, тынычландыра? (Сабантуй, алга таба – С.)

г) дөрес булмаган фикер әйтү һәм әлеге фикернең әңгәмәдәш тарафыннан кире кагылуына ирешү (әйтик, түбәндәге очракта журналист белә торып булмаган факт турында сорау бирә):

- Концертта нинди бүләкләр бирделәр соң? (М.)

Әңгәмәдәшнең фикерен үстерүгә һәм куәтләүгә юнәлдерелгән репликалар да интервьюның җанлылыгын, табигыйлеген көчәйтә.

Алда әйткәнебезчә, интервьюда телнең теге яки бу чаралары жанрның төренә, әңгәмәнең нинди шартларда узуына, әңгәмәдәшнең характеры, сөйләм үзенчәлекләре, журналист каләменең үткенлегенә бәйле рәвештә кулланыла. Рәсми интервью, нигездә, тулы һәм туры җөмләләр белән» рәсми стиль лексикасы һәм әйләнмәләре, газетизмнар кулланып язылса, интервьюның рәсми булмаганнарында сөйләү стиленә хас лексик һәм грамматик чаралар еш очрый. Бу жанрның барлык төрләрендә дә әндәш сүзләр һәм перформативлар («рәхмәт», «гафу итегез», «котлыйм» кебек сөйләү моментын ассызыклый торган сүзләр) актив кулланыла. Әңгәмәдәшнең сөйләү үзенчәлекләрен язмада чагылдыру журналисттан аеруча игътибар һәм тырышлык таләп итә.

Гомумән, интервью жанрында иҗат итүченең осталыгы, актуаль һәм кызыклы әңгәмә оештырып, аны газета битенә мөмкин кадәр төгәл һәм табигый итеп күчерә белүдә күренә.

Контроль сораулар:

1. Интервью жанрында иҗат итүнең төп үзенчәлекләре нинди?
2. Интервьюның эчтәлегенә йогынты ясаучы төп факгорларны атагыз.
3. Бу жанрның төрләрен санап чыгыгыз.
4. Интервьюның композицион һәм тел-стиль үзенчәлекләре турында сөйләгез.

Биремнәр:

1. Үзегез укыган берәр интервью буенча әңгәмә барышына йогынты ясаган факторларны ачып бирегез.
2. Берәр тәҗрибәле татар журналистының интервью иҗат итү алымнары белән танышыгыз. Шул хакта кыскача чыгыш әзерләгез.
3. Хрестоматиядән укып, интервьюның классик үрнәкләре белән танышыгыз.

ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

Васильева Л.А. Делаем новости! - М.: Аспект-Пресс, 2002. -190 с.

Воскобойников Я.С., Юрьев В.К. Журналист и информация. – М.: РИА «Новости». 1993. – 204 с.

Гарифуллин В.З. Вакытлы матбугатта жанрлар. – Казан, 2007. – 121 б.

Гарифуллин В.З. Хәбәри жанрлар. – Казан, 1991. – 44 б

Гарифуллин В.З. Язар сүзең булса… - Казан, 2000.- 204 б.

Информационные жанры газетной публицистики: Хрестоматия / Под ред.В.Д.Пельта. – М.: Изд-во Моск. ун-та, 1986. – 296 с.

Низамов И.М. Матбугатның тәэсирле сүзе. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1981. – 144 б.

Пельт В.Д. Дифференциация жанров газетной публицистики. – М.: Изд-во Моск. ун-та, 1984. – 48 с.

Репортер осталыгы: Хрестоматия. – Казан, 1992. – 48 б.

Теория и практика советской периодической печати/ Под.ред.В.Д.Пельта. – М.: Изд-во Моск. ун-та, 1980. – 260 с.

Тертычный А.А. Жанры периодической печати. – М., 2009.

Шостак М.И. Репортер: профессиноализм и этика. – М.: РИП-холдинг., 2001. – 165 с.

ӨСТӘМӘ ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

Агзамов Ф.И. Единство двух начал//Единство информации и анализа в публицистике: Сб. статей. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1974. – С.3-15.

Борецкий Р.А. Информационные жанры телевидения. – М.: Высш.шк., 1961. – 75 с.

Вакуров В.Н., Кохтев Н.Н., Солганик Г.Я. Стилистика газетных жанров. М.: Изд-во Моск. ун-та, 1978. – 184 с.

Васильева Т.В. и др. Теле- и радиоинформация. – Л.: Изд-во Ленинград. ун-та, 1987. – 67 с.

Дугин Е.Я. Информационно-публицистические передачи телевидения и пути повышения их эффективности. – М.,1989. – 207 с.

Жанры советской газеты. – М.: Политиздат, 1976. – 176 с.

Одинец М.С. Ради нескольких строчек в газете… - Киев: Вища шк., 1989. – 157 с.

Пальгунов Н.Г. Заметки об информации. – М.: Изд-во Моск.ун-та, 1987. – 104 с.

Пельт В.Д. Заметка как газетный жанр. - М.: Изд-во Моск.ун-та, 1984. – 48 с.

Сагал Г. Двадцать пять интервью. – М.: Политиздат, 1978. – 285 с.

Смирнов В.В. Жанры радиожурналистики. – М.: Аспект Пресс, 2002. – 288 с.

Стилистика газетных жанров /Под ред.Д.Э.Розенталя. - М.: Изд-во Моск.ун-та, 1981. – 230 с.

Стрельцов Б.В. Основы публицистики. Жанры. – Минск, 1990. – 239 с.

Хәбәрче буласың килсә…/Төз.И.Сәмигуллина. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1984. – 96 б.

Шостак М.И. Журналист и его произведение. – М., 1998.

Шумилина Т.В. «Не могли бы Вы рассказать»… - М.: Изд-во Моск. ун-та, 1976. – 136 с.